# ОСТАЗБИКӘ

Сәгыйдә остазбикәдә бер дә артыклык-кимлек юк иде. Ул гади генә авыл остазбикәсе иде. Аның кияүгә чыгуы да муллаларда булганча гади генә булды. Ул кыз булып үсеп килә башлагач та төрле йирләрдән мулла, мөәззингә, мулла сыманрак булырга тырышкан байларга сорарга тотындылар. Әтисе хәзрәт, мужик халкын яратмаганга, мөәззиннәрне Хуҗа Насретдин хәзрәтләренең мәгълүм ишәге тупрагыннан яратылган дип игътикат иткәнгә, һәммәсенә сүз кайтара килде.

Абыстай кай вакытларда Сәгыйдәнең буйга җитеп егермегә басуыннан курыккаласа да, хәзрәт, тәкъдире язганы булыр дип ышанганга, һаман үз сүзендә торды.

Менә, еракта гына булса да, яңа указ алган бер муллага Сәгыйдәне сорарга килделәр. Остазбикә булачак авылы кара як булганга, сораган яшь мулланың атасы тирә-юньдә наданлык берлән шөһрәт тоткан Рәхим мулла булганга, кардәш-кабилә әүвәлдән үк чит күрделәр. Ләкин хәзрәт үзе кияү булачак шәкертне әллә кайда гына — шәһәрдәме, Казан юлында парахуттамы — бер мәртәбә күреп ихлас баглаганга, «киңәш итешик» дигән җавапны бирдертте вә башкода булып килгән Фәхри мөәззин артыннан ук, абыстайның туган кардәшен ат җиктереп шул авылга, «югалган атны эзләргә» җибәрделәр... Яшь мулланың бөтен хәле-әхвале, надан Рәхим мулланың хатын, бала-чагасы, мәхәллә халкы, мәхәлләнең яшь муллага карашы, тирә-юнь муллаларының яшь муллалардан өметләре хакында тулы мәгълүмат китерергә куштылар.

Шундый зур мәсьүлиятле эш белән бара торган Шакир мөәззин, егерме елдан бирле икенчегә өйләнергә ниятләп, кыз эзләп йөргәнгә, эш арасында эш эшләнер дип, хәзрәтнең тамак толыбын, сатучы Шәмсинең чуар итеген киенеп, сәфәргә чыкты.

Юлда, утырып калган карт кызлы Шәмсетдин хәзрәткә кереп, кунып чыкты. Үзенең, мөәззин булса да, имам могыйнь, лявазим имам икәнен, хәзрәтнең фидия алмавы аркасында кулы иркенелеген, гошернең дә шактый

күп килүен сөйләп, ләкин җәмәгатенең генә, шул, үзенә муафикъ булып йитмәгәнен, үлек юганда су салып торырлык кадәр мәгълүматы булмавын, кадер кичәсендә, гарәфә көнендә хатын-кызга вәгазь-нәсыйхәт сөйләрлек укымышы юклыгын белдереп: «Хәзрәт, Аллаһе Тәгалә менә үземезгә муафикъ җәмәгать мөяссәр итсә иде дип догада булсаңыз ла!» — диде.

Хәзрәт, догада булса да, кызын бирергә нияте барлыгын белдермәгәнгә, Шакир мөәззин шуннан унике чакрымда тол кызлы бер байга да ат ашатып чыгарга керде... Анда да, кич белән ястүне укып, чәй эчеп утырганда, үзенең дәрәҗәсенә җитеп, мәрхүм Закир дамеллага «күңел сабагы»на утырганнан башлап, авыл халкы үзен мулла итәргә бик тырышса да, кыямәт көнне, Билал разый Аллаһе ганһенең ливасы астында кубудан калмас өчен мөәззинлекне ихтыяр иткәнен сөйләде: «Аллага шөкер, үзе бик яхшы тора, ләкин Аллаһе Тәгаләнең хикмәте — җәмәгате, бик укымышлы булса да, бәйрәмнәрдә «Дөррәтеннасыйхин», «Мөхәммәдия»не ярып салса да, үлек өстендә аңарга башка мәет юылмаса да, сәламәтлеге начар булганга, өй тәрбиясе итә алмый. Хәтта, менә хәзер, хәлифә хәзрәткә «зикер яңартырга» барса да, күңеленнән, шул, җәмәгате «үлде» дигән хәбәр килмәсен дип, куркып кына бара».

Бай сатучы, шундый, хатыны үлем якасындагы мөәззиннәрне, указ алып мулла булырга авыл табылып та, приговоры җыелып, имтиханы гына кирәк муллаларны ай саен кебек күреп торганга: «Аллаһе Тәгалә, шул, ничек тә бер яклы ясасын инде, болай хәлеңез авыр икән!» — дигән җавапны кайтарды.

Аннан соң, барачак авыллардан шундый өметле йирләр булмаганга, Шакир мөәззин яучы килгән авылга килеп қитте. Мәсҗедтән ерак түгел генә, таза гына бер мужикка кунакка туктады. Үзенә кыз таба алмаганга, бик ихлас белән, кияү булачак мулланы, атасын, анасын, мәхәлләсен белешергә кереште.

Өй хуҗасы үткен генә мужик, бик тиз бу хәзрәтме, мөәззинменең ник килгәнен сизеп алып, турыдан-туры сөйләде. Шакир мөәззин аның сүзеннән карт мулланың кирәк үзе, кирәк җәмәгате абыстайның гади мужик икәнен, яңы мулланың бик һәйбәт укымышлы, инсафлы шәкерт икәнен аңлады. Мәхәлләне

күзе берлә күрер өчен, Шакир мөәззин авылның теге очына да төшеп китте. Анда барганда муллаларның өе яныннан үтеп, йорт-җирләрен, тормыш-килешләрен өстеннән генә күздән үткәрде.

Түбән очтагы ат сатарга тели торган яшь егет тә мөәззин абзыйны бик тиз танып алды. Бу да йорт хуҗасының сүзләрен беркетте. Ләкин шуның өстенә: «Абзый кеше! Шунысын әйтәм: берүк ул йортта килен булып чыдар өчен кызыңыз шәйтан тиресе киеп килсен!» — диде. Шуннан соң абыстайны сөйләргә кереште.

Иртә белән Шакир мөәззин иртә намазга керде. Кечкенә генә тәрәзәле, караңгы гына мәчет үзенең сәләмә намазлыклары белән бик фәкыйрь төсле күренсә дә, яшь мулланың сузып кына, яхшы гына кыйраәт белән имам булуы шактый күңелгә тулды. Ул, иртә намаздан соң ишракъ намазы уку гадәте булса да, яшь мулла белән күрешер өчен бергә чыкты вә башмаклыкта сәлам биреп күреште дә.

Яшь мулланың: «Сез кай ягы буласыз, кунак?» — дигән сөаленә Шакир мөәззин муллаларча иттереп, гарәпчә катыштырып: «Без, мәхдүм, монда фи сәбили Аллаһ йөри торган мөсафир гына... Хәлифә хәзрәткә зикер яңартырга барамыз». /*/ авылыннан,— диде. Шул авылның исемен ишеткәч, яшь мулланың йөзенә кызыл йөгерде. «Бу кем?» дигән сөаль аның башына килеп җитеп, «кем булса да, мине күрергә килгән кеше!» дип, имтиханда булган кебек кабзыятьләнебрәк китте. Сүз шунда туктаганда гына Шакир мөәззиннең кунак өе хуҗасы: «Мулла! Безгә чәй эчәргә керик лә. Кунак та менә бездә, мулла кешеләр, сөйләшеп утырырсыз», — диде.

Яшь мулла әллә нинди, хәл итеп булмый торган бер мәсьәләгә терәлеп калган кебек булганга, мужик сизеп: «Мин хәзрәткә Вахидны йибәргән идем. Ул хәзер килер»,— дигәч тә, яшь мулла, җиңеләеп китеп, алга атлады.

Озакламады, дублы туннан, биленә билбау буган бер кеше керде. Мулланың сикереп торуыннан, өй хуҗасының: «Әйдәңез, хәзрәт!» — дип каршы алуыннан шул мужикның эчендә кода хәзрәт яшеренеп торганлыгын

Шакир мөәззин күреп алды. Мәҗлестәге сүзләр дә, аннан соң муллаларның үзләренә баргач та ашалган ашлар да — һәммәсе бер сүзне беркетте.

Шул сүзне алып, зикер яңартыр өчен хәлифәгә барганын онытып, үзенең хатын бүген-иртәгә үләсе булганга өйләнергә теләгәнен дә хәтереннән чыгарып, Шакир мөәззин өйгә чапты.

Шакир мөәззиннең китергән мәгълүматы абыстай, кардәш-кабиләне канәгатьләндермәсә дә, хәзрәт үзе бирү ягында булганга, бөтен кардәш-кабиләне җыеп, кичке ястүдән соңгы озын киңәш мәҗлесендә килен итеп төшермәенчә, аерым тору шарты белән бирергә карар чыгарылды.

Вә шул шартларга разый булгач, бирелде дә.

Туйлары ничек булганын Сәгыйдә, әлбәттә, бөтен вакларына кадәр хәтереннән чыгармады. Ләкин кияү көткән көн бигрәк каты итеп аның күңелендә сеңгән: кодалар килгәндә ул, кечкенә өйдә булганга, каенатасын да, каенанасын да бердән күрмәде. Ирләр чәй эчәргә утыргач кына, кодагыйны югары өйгә алып менгәч кенә, ул ярыктан беренче мәртәбә карады. Хәзер дә күз алдында: иң түргә, мулла җизнидән дә югарыга, бер таза кеше утырган; өстендә әллә нинди, мужик баендагы кебек, кытатмы, манчестермы казаки, башында старостаныкы кебек укалы такыя, кулында зур гына, акайган гына мужик киленнеке кебек яулык. Менә ул шул яулык белән бик кычкыртып борынын сөртте. Бу кем икән? Кара әле, мулла җизни: «Яңез, кода хәзрәт», — диде. Шул сөйкемсезмени?.. Менә сөйләргә тотынды. Теле гомердә мәдрәсә күрмәгәнме, аю уйнатучы мишәрмени, «да, да...» дип тора.

Әстәгьфирулла, әстәгъфирулла!

Сәгыйдәнең күзенә яшь килергә өлгермәде, зур абыстай килеп: «Әйдә, тәһарәтең бармы? Каенанаңа күрендерергә», — дип, җилтерәтеп алып китте. Сәгыйдә тын алырга, хәл җыярга өлгермәде, «бисмилла» дип бер ягыннан олуг тутасы, бер ягыннан карт җиңгәсе тотып, аны кодагыйларның чәй мәҗлесенә китереп бастырдылар вә бисмиллалар, салаватлар белән: «Кодагый абыстай, киленеңез!» — диделәр. Сәгыйдә ничек күрешкәнен белмәде. Куллары догага күтәрелгәндә дә ни укыганын хәтерләмәде. Тутасының төртүеннән соң

каенанасына сигез чирекле ефәк яулык биргәнен дә, каенанасының зур ике талир тәңкә бүләк иткәнен дә рәтләп сизенмәде. Шул гадәтләр, йолалар бетеп, аяк өстендәге Сәгыйдәгә әнисе: «Утыр, кызым», — дип, йомшак кына әйткәч, Сәгыйдә уянып киткән кебек булды. Ул, акыртын гына самавыр артына утырып, күзен күтәрде.

Түрдә киң генә битле, урта яшьле бер хатын утырган. Чынаякны, алганда аның алдына таба зур, озын яка чылбырлары, берсенә берсе бәреләбәреләә, алга таба бөгеләләр. Күкрәгенә кушып кигән, ике кул иңле укага тезелгән хәситәдә төрле зурлыктагы тәңкәләре шалтырашып акаеп торалар. Колакларындагы хәзерге заманның чулпысы кебек, колак алкалары болай да зур колакларын басып, сәлеңдереп торалар. Ул бер-бер әйбер алыр өчен селкендеме, аның артындагы озын чәч такмасы, аларга тагылган зур чулпылар, кыңгырауны тайлар җыелган кебек, шылдырау тавышлары чыгаралар. Кулларының саргайган тиреләре өстендә берсеннән берсе киң, әллә ничәшәр беләзекләр аның кулларын сынганнан калайлаган чәйнек борын кебек иттереп күрсәтәләр. Юан-юан бармакларда зур ахаклар, фирәзәләр, прастуй кызыл ташлардан ясалган кашлы, төрле төстәге, алды-артлы киелгән өчәр-дүртәр йөзекләр аның бармакларына кырык тартмачыдагы сатар өчен төрле төстәге, төрле буяудагы йөзекләр утырткан агач төсен бирәләр.

Шул бизәнү генә аз кебек күренгән булырга кирәк, кодагый ап-ак иттереп акшар белән битенә кершән яккан. Инлек белән бит урталарын кызартып, аны буяган чиләк төбенә охшаткан. Тешләренең аклыгы шул матур йөзгә, шул кием-салымга килешеп бетмәс дип уйлаган булырга кирәк, ул атныкы кебек зур-зур тешләрен карага буяган!

Сәгыйдә бер мәртәбә карады: үзенең каенанасы шул булуга ышанмады.

Икенче мәртәбә карады: үзенең әнисенең кодагые шул булуга ышанмады.

Сәгыйдә өченче мәртәбә карады: бөтен затсызлыкларны тутырып киенгән шул хатынның мулла хатын булуына, бер яшь мулланың анасы булуына ышанмады.

Тутасының ясаган чәен авызына ала алмыйча, ул һаман шуңарга карады. Хикәяләрдә сөйләнә торган убыр карчыгына охшаган куркыныч каенананың ничек сөйләвен ишетер өчен, торып китмәде, китә алмады. Шуны ишетәсе килүе, шуны беләсе килүе аның бөтен йөрәгендә кайный торган күз яшен буып тотты.

Менә ул авызын ачты, аның кара тешләре ыржайды, аның өстләренә элгән төрле тәңкәләре, челтәрләре,төймәләре хәрәкәткә килеп, йәшел-йәшел тавышлар чыгарды; Сәгыйдә үзенең колагы белән каенанасының тавышын ишетте. Ул тавышны ни дип әйтергә?.. Ул аны аңлатырга әле дә сүз таба алмый. Ул Сәгыйдәнең моңынча күргән һичбер кешенең тавышына охшамаган кебек, Сәгыйдәнең һичбер төрле кош-корттан да ишеткән тавышына да туры килми. Ул карт урысның йомшак иттереп, матур татар хатын булып сөйләргә теләгән кылыншына гына аз гына охшый.

Ул, шул әфәлем төрле тавышны ишеткәннең соңында, тагы чыдарга тәкате калмаганын белеп, акыртын гына торды. Ишеккә барып ниткәндә, аның ике күзеннән дә яшь куып җитте. Ул кызу-кызу баскычтан төшеп, караңгы бүлмәгә кереп, акырып-акырып еларга тотынды. Аның артыннан тутасы, аннан соң килгән анасы да аны бастыра алмады. Ул элгәре тавышсыз еласа да, ахырга таба теле ачылып: «Ни генә гөнаһым булды икән лә, Раббем! Нинди генә кешенең күз яше төште икән лә, Ходаем! Нигә генә бу бәлагә грифтар булдым икән лә!» — дип көйләргә тотынды. Бераздан соң: «Нигә соң миңа ул кадәр дошман булдыңыз, әй этием, әй әнием, нигә соң мине урамга гына чыгарып ыргытмадыңыз, нигә генә соң мине үстердеңез?» — дип ыңранырга, сыкранырга кереште.

Тутасының: «Угыллары боларга охшамаган», — диюләре, анасының: «Атаңнан курык, кунаклардан оял!» — диюе дә тәэсир итмәде, Сәгыйдә елавында дәвам итте. Кодалар белмәсә дә, абыстай үзе, Сәгыйдәнен тутала-ры, бөтен кардәш-кабиләсе пошындылар, кайгырдылар. Хәзрәт Сәгыйдә белән үзе сөйләп карамакчы булды. Ләкин Сәгыйдә, этисенә каршы сүз сөйләргә өйрәнмәгәнгә, бер сүз дәшмичә, акрын гына елавында гына булды. Хәзрәт, зур

сүзгә сәбәп булачак булса да, туйны туктату ягын сөйләргә тотынды. Ләкин Сәгыйдәнең тутасы: «Әти, кирәкмәс. Бик матур төш күрдем», — дип, этисенә ялынганга вә бертуктамыйча: «Боларның мужик икәнен бит без үземез дә белдек. Угыллары охшамаган, ди. Казан шәкерте, ди. Менә хәзрәти Ибраһим бит, санәм сатучының баласы булган. Хәзрәти Муса бит, Фиргавеннең тәрбиягә алган угылы булган... Төшем бик матур иде... Сабыр ит, Сәгыйдә, Алла теләсә, бөтенләй уйламаганча чыгар», — дип димли-димли башын әйләндергәч кенә, Сәгыйдә, күңеленнән ышанмаса да: «Беткән баш беткән!» — дип, туйны туктатмасыннар дидертте.

Никях мәҗлесе дә шактый салкын үтте. Кодалар, кодагыйларны сыйлау да күркәм үтмәде. Кодаларны озаткан атлар кияүне алып киләсе булганга, Сәгыйдә иртәдән үк ап-ак балавыз кебек агарып, гомерләре бергә үтәчәк иптәшен көтәргә тотынды. Аның күз алдында теге затсыз авыл старостасы төсле карт белән түбән очның юлаучы кертүче Гыйззетбануы кебек карчык басып торганга, аның хыялы күптән инде шуларның икесеннән кушып бер егет — бер кияү ясап куйды. Ләкин шулай булса да, күңелнең кырыенда кечкенә генә, нәни генә бер өмет бетмәгәнгә, вакыт якынылашкан саен аның күңелендә курку белән өмет зурая барды.

Менә кыңгырау тавышы ишетелде. Атасы, анасы, агасы, мулла җизнәсе — барысы да, салаватлар әйтеп, капкага таба киттеләр. Әнисе, «Бисмиллаһи әлләзи...» укып, Сәгыйдәнең йөзен сөртеп, күзеннән аккан яшьләрен тыя алмаенча, чыгып китте. Сәгыйдәнең тутасы, авыз эченнән әллә нинди догалар укып, Сәгыйдәнең боздан салкын кулыннан тотып, капкага таба —актык өметкә таба күзен текәде.

Кыңгырау якынылаша башлагач, Сәгыйдәнең тәннәре калтырарга, тешләре шакылдарга тотынды. Төне бер җыерылып, бер киерелеп, зыяндаш тоткан кебек булды. Күзләренә әллә нинди ут керде.

Менә капка ачылды. Кыйбла яктан повозкалы атлар чабып килеп керде. Повозка янына — сафланып чалма-чапаннан тора торган Сәгыйдәнең этисе, җизнәсе янына сикереп кияү төште.

Башындагы ак данадар бүреге, өстендәге шәһәрчә тегелгән постау җиләне, аякка кигән пөхтә кәвешләреннән йөгереп, бик тиз Сәгыйдәнең күзе битенә, төсенә төште. Яңа гына мыек чыгып килә торган таза-яшь йөз, йөзендәге үткен генә кара күзләре, җиңел генә хәрәкәтле сабыр гына кыяфәтне Сәгыйдә бердән күрде. Шул күрү белән аның җилкәсеннән зур бер йөк төшкән кебек булды. Аның котын алган шул кодагый белән коданың сыйфатлары бердән югалды. Аның күңелендә зур өмет, җылы өмет туды. Кулы бердән җылынып китте. Көн бердән матурайган кебек булды. Ул, нишләргә белмичә, якындагы тутасын (гадәттә үбү булмаса да) кочаклап үпте.

Менә ишек ачылды. Әтисе, мулла җизнәсе керде. Әнә ят бер тавыш. Аның тагы йөрәге куркып китте. Моң гына, саф кына яшь ир тавышы.

Сәгыйдә: «Йа Раббем! Бәхетемне ким кылма!» — диде дә, этиләре чыгып китү белән тазарып, батыраеп күрешергә чыгарга хәзерләнде.

***

Сәгыйденең кияү бүләге чыгаргандагы көләчлеге, ачыклыгы тутасыннан анасына, анасыннан атасына җитеп, бөтен авылны йөреп чыкты. Дүртенче көнне әтисе хәзрәт белән әнисе кияү хәзрәт белән күрешергә кергәндә, Сәгыйдә, ата-анасыннан оялудан, күзен итәгеннән күтәрмәсә дә, карт белән карчык мулла кияүнең ачыклыгыннан, бертуктамаенча «Сәгыйдә, Сәгыйдә» дип торуыннан, башлары күккә тиеп чыктылар.

Кияү китеп ике көн үткәч тә Сәгыйдә сузып-сузып «Мөхәммәдия» укырга тотынды. Дүрт көн үткәч тә мулласы килә торган юлга еш-еш карангалый башлады. Алырга атлар йибәргәч, ул үзенең шатлыгын анасыннан, атасыннан да яшерә алмады. Кияүлек вакытлары үтеп барган саен, Сәгыйдә мулласын ярата барды. Танышлыклары озайган саен, Сәгыйдәге мулласыннан аерылу авырая барды. Ул тәмам хикәяләрдәге кебек иттереп мулласын сөйде, мулласына гашыйк булды.

Туй алдында аның куркулары, аның каенатасы белән каенанасын күргәннән соң көне-төне бербуйдан елаулары әллә кайчан онытылды, әллә кая гына, хикәядә булган шикелле генә, томанлы гына бер нәрсә булып калды.

Җәй буе кияүләп, көз җитә башлагач та, Сәгыйдә хәзрәтеннән атна-ун көн аерылып торуларның авырлыгын бик нык сизенә башлады.

Атасы, анасы, кияү хәзрәтнең үзенең йорт-йирләре булып җитмәенчә төшмәсен әле дип, Сәгыйдәне шул затсыз кода-кодагыйга килен иттерәселәре килмәсә дә, кияү хәзрәтне быелгы гошере белән өй салырга димләп, киләсе җәйгә үз йортларына төшерүне мәслихәт тапсалар да, кияү хәзрәт үзе дә шул якта булса да, Сәгыйдә, кышкы озын төннәрдә ялгыз — кияү хәзрәтсез булуы уеннан коты очканга, бөтен юллар белән китәргә тырышты һәм дә көзге казлар суюдан элек килен булып төште дә.

Көзнең күзгә төртсәң күренмәс төннәрендә мулласы белән карабодай ташуның уңайсызлыгын да, көзнең көз буенда алтылап ике ындыр табагында ашлык сугучыларны ашатуның күңелсезлеген дә, көне-төне лыр-лыр лыгырдап йөри торган каенанасының эч пошыруының авырлыгын да ул сизмәде.

Үз бүлмәләренә кереп, үзләре генә калгач, хәзрәте Габделвахид белән ялгыз гына калгач, ул бөтен аруларны, тиргәүләрне — һәммәсен оныта торган булды. Үзенең сөю-сөелүенә чума торган булды. Шул бәхет, шул тынычлыктан иртәгәге мәшәкатьләргә, иртәгәге тынычсызлыкларга хәл-көч җыя торган булды.

***

Бәлки, шулай итеп Сәгыйдә гомергә дә килен булып калыр иде, бәлки, гомергә дә ул шул хезмәтчеләр ашата торган, сарыклар карый торган, сыерлар сава торган, карт белән карчыкның комганнарыннан җылы суны бушатмый тота торган асрау да булып калыр иде.

Үзенең бер карт мулланың кадерле кызы, бер яшь мулланың сөйгән остазбикә хатыны икәнен онытып, шул затсыз карчык белән мужик каенатага асрау булганын да сизенмәгән булыр иде. Бәлки аның иренә мәхәббәте шундагы бөтен авырлыклар, бөтен хурлыкларны оныттырып, аңарга тормышның бөтен әчесен төче иттереп күрсәтер иде. Ләкин тормышта бик күп эшләр уйламаганча чыккан кебек, бу юлы да көтелмәгән эш хәятны борып йибәрде.

Беркөнне Сәгыйдә сарык абзарында бәрәннәр карап йөргәндә, капка төбенә бер атлы килеп туктады. Атның көлдерәтеп кешнәве Сәгыйдәнең әтисенең акбүз айгырын искә төшергәнгә, ул кулына кое суы чиләге күтәреп йортка таба чыкты. Ул чыкканда атлы капкадан килеп кергәнгә, карга буялган чаналардан, авызы-борын тирәсенә кар каткан атның башларыннан кемлеген танымаенча аптырап торса да, чананың артыннан капканы ябып килә торган тамак тунлы атасын күргәч, Сәгыйдә катып калды.

Әтисе бу көенчә күрә күрмәсен дип, лапас астына керергә өлгермәде, карт хәзрәт: «Кызым, синме?» — дип, каршы килде. Сәгыйдәнең кулыннан чиләге төште, аның артыннан кулындагы зур баригасы җиргә тамды. Ул, аптырап әтисенә кулын бирде. Карт хәзрәт: «Исәнме, кызым! Исәнме?» — дип, берничә дәшсә дә, күзен кызыннан ала алмады. Аның ике күзеннән агып киткән яшь бөртекләре сакалы, мыегы янына каткан карлар янына килеп туктады.

Карт хәзрәт кызын, үзенең сөекле кызын өстендә дублы мужик туны, кулында ярты аршинлы баригалы, башында ирләрдән калган мескен бүрекле, аягында тула оек өстенә юкәдән үреп ясаган башмаклы иттереп күрү хәйран калдырды.

Ул, тагы әллә ни әйтергә теләсә дә, күзеннән тагы яшьләр тәгәрәгәнгә, бер сүз дә эндәшә алмады. Сәгыйдә дә, бу уйланылмаган кунакка көтелмәгән кыяфәттә туры килүеннән, аптырап калды.

Хәзрәт, бераз батырланып, акрын гына тавыш белән: «Мулла Вахид кая соң, кызым?» — диде. Сәгыйдә уйлап та тормыйча: «Алар, әти, әвен сугалар»,

— диде дә, үзе дә, үз якларында, үз кардәш-кабиләләрендә, дуст-иш муллаларында һич булмый торган бер эш белән кияү хәзрәтне тәкъдим итүгә кызарып та китте.

Карт хәзрәт: «Алай икән, кызым! Син әвен сугарга чыкмадыңмыни?..» —диде дә озын гына иттереп кызын сөзде.

Шул сөзүгә җавап кебек, аның күзеннән тагы ике бөртек яшь тәгәрәде.

Кинәттән, бик каты иттереп, тәрәзә како̀анлык ишетелде. Сәгыйдә калтырап китеп югалды. Хәзрәт атын бәйләп куеп, ишеккә таба борылса да, бик озаксыз ишек ачылмады.

Өйгә кергәч тә карт хәзрәт, Рәхим мулланың түрдә утырганын күреп, аптырап калды.

Мулла Вахид икендесез кайта алмады. Ул да каенатай хәзрәткә чабатадан, билдә алъяпма булган кыяфәттә очрап оялды. Ләкин карт хәзрәт, бераз йомшап киткәнгә, аңарга кызгану күзе белән карап: «Исәнме, мулла Вахид», — диде.

Каенатасы хәзрәтнең үзләрен шулай табудан мулла Вахид хурланды. Атасының: «Мин кыз бирмәдем. Кыз алдым!» — дип, илтифат итмәгән булып, түр башында мокыт булып утыруына ачуы килде.

Ул ахшамга барганда хәзрәткә хәлләрен аз гына аңлатты. Ахшамда карт хәзрәт үзе имам булып укытты, мәчеттәге мәхәллә картлары белән күрешеп: «Сезнең кайсыңыз монда әле Шөгаеб була?» — диде. Бер бөкре генә карт: «Мин, хәзрәт!» — дигәч, «Сезмени?» — дип, аны читкә алып: «Син, Шөгаеб ага, ястүгә ат җиктереп чыгар да, карчыгыңа самавыр куярга кушып кил, синә барып чәй эчик әле!» — диде.

Ястүдән соң карт хәзрәт Шөгаеб абзый белән атка утырып түбән очка төшеп киттеләр. Анда тагы сорашып, авылның игътибарлырак картларын чакыртып, биш-ун кеше арасында хәзрәт: «Җәмәгать! Минем сезгә йомышым бар иде», — дип, сүзгә кереште.

Хәзрәт, сүздән элек шактый йомшарып куйгангамы, аның сүзләре йомшак кына хәтфә кебек чыкты. Ул: «Җәмәгать! Мине таный торгансыз: мин

сезнең кодаңыз. Яңы остазбикәңезнең атасы Хәйретдин мулла булам. Сезнең авылга дүртенче кызымны кияүгә бирдем. Әүвәлге өчесе дә, әлхәмделиллаһ, михраб иясе имамнарда, өчесе дә, әлхәмделиллаһ, авылларның кызларын укытып, бәйрәмнәрдә вәгазь әйтеп, мәхәллә халкына хезмәт итеп торалар. Безнең нәселдә, җәмәгать, Аллага шөкер, бер дога бар. Безнең мәрхүм әтиемез әйтә иде: «Миңа бер юлаучы бервакытны «балаң-чагаң ил хезмәтчесе булсын, дип, дога кылгач, угылым, кызым староста, дисәтник булып, куштан булалар күрәсең, дип курыккан идем. Хәзер, әлхәмделиллаһ, сине михраб иясе күргәч, күңелем тынды» дия иде. Менә шулай, җәмәгать, мин кызымны мулла Вахидкә биргәндә анасы да, кардәш-кабиләмез дә, авыллары кара, укыган, хезмәт итәчәк остазбикәгә мохтаҗлар, дин өйрәтер, намаз-ниязга алыштырыр дип уйлаган идек. Бабаларының да догасы шул иде, — шуннан соң хәзрәтнең күзенә яшь тыгылды, — әлхәмделиллаһ, биргәненә шөкрана. Мулла Вахидтә бер сүз юк. Гыйлеме бар. Истикамәтендә. Ир Вазыйфасын белә... Ләкин, җәмәгать! Мин кызымны монда Рәхим мулланың сарык абзарын тазартырга бирмәдем. Сез дә муллаңызны алты белән әвен сугарга дип алмагансыз?..»

Мужиклар, үзләрендә гаеп бар кебек хис итеп, башларын бөктеләр. Берсе генә: «Хәзрәт, бездә гаеп!» — диде.

Хәзрәт: «Юк. Сездә гаеп түгел. Монда безнең кода хәзрәттә гаеп», — дигәч, мужиклар бердән «шулай, шулай» дип сөйләшергә тотындылар.

Сөйли торгач, хәзрәт: «Менә быел, яшь муллаңыз — яңа муллага йорт-йир кирәк дип, сез, ил картлары, гошереңезне аңарга бирергә кирәк иде. Ул, менә, кечкенә булса да йортлы-йирле булыр иде. Үзе мәдрәсәңездә укытыр иде. Җәмәгате кыз балаларыңызны сабакка йөретер иде», — диде. Җәмәгать бердән: «Хәзрәт! Шулай иттек бит, карт хәзрәт бит, аңарга дигәнне барыбер үзенеке белән бергә куйдыртты. Без бит, ата белән угылы арасына керә алмыймыз», — диделәр. Озын сүздән сон мәхәллә картларына хәзрәт: «Җәмәгать! Менә ничек булса да мәчет тирәсендә муллага бер йорт алырга кирәк», — диде. Картлар, үз арада яңадан гошерләрен җыеп, йөз потлап арыш

язылдылар; мәчет күршесендәге, бер генә өйле булса да, шактый зур җирле Шәмсетдиннең йортын сатып алырга да булдылар.

Шул киңәшне беркетер өчен мулла Вахидне дә: «Әни авырып киткән иде. «Ясин»га чакыра идем», — дип алып та килделәр. Аның да ризалыгы белән икенче көнне үк мәхәллә картлары, тагы авылдан ашлык җыеп, Шәмсетдиннең йортын сатып та алдылар.

Хәйретдин хәзрәт үз күзе белән кызы, киявенең үз башларына тора башлаганын күрер өчен, иң дөресте, үзе бетереп китмәсә, очлый алмаслар дип куркып, үзе өйне яктыртты. Үзе кушып идәннәрен юдыртты. Өченче көнне, җомга көн, берни дә белешмәгәнгә салынып тора торган кодадан рөхсәтне дә үзе сорады. Коданың, кодагыйның кычкыруы-бакыруына карамаенча үзе үк күчереште.

Икенче көнне үзе үк иртәге намазында: «Җәмәгать! Кыз балаларыңызны укытасыңыз килсә, яңы остазбикәгә балаларыңызны китереңез. Укыту фи сәбил Алла! Иншалла, белгәне кадәр намаз-нияз үгрәтер», — диде.

Дүшәнбе көнне авылның төрле очыннан табак-табак оннар, икмәкләр, итләр күтәреп килгән кыз балаларны, кызы Сәгыйдә «бисмилла» әйтеп әлиф-бигә төшергәнне, күңел сабагына «Әлхәмде» сүрәсен биреп җибәргәнне күреп, Хәйретдин хәзрәт тынычлап өенә кайтып китте.

Шул көннән башлап Сәгыйдә белән Вахид мулла аерым бер хуҗа булып, аерым бер мулла булып тора башладылар.

***

Яңы өйдә, яңы йирдә яшь мулла белән яшь остазбикәнең тормышлары бөтенләй башка төс алды. Иртә белән, таң атар-атмас, авылның төрле очындагы нәни кызлары букчалар күтәреп ишекне шакый башлагач та икесе дә аякка калкалар. Хәзрәт, тәһарәт алып, мәчеткә юнәлә. Остазбикә дә,

тәһарәтләнеп, балалар укытырга керешә. Балалар сабагы арасында ул намазын да укып ала; балаларга мәгънәле сабакны бирә-бирә генә сыерын савып ала.

Көн ачыла-ачыла кызлар берәр китапларын белеп, икенчеләрен алалар, бик үк үткеннәре өченчесен белеп бетереп, абыстайның мичен ягарга, мулла абзый кайтуга самавыр куярга тотыналар. Кайсылары күрше Закир бабай коесыннан абыстайның сыерына су китерәләр; кайсылары ындыр арты чишмәсеннән мулла абзыйга эчәргә чәй суы алып кайталар. Кызлар укып бетергәч, абыстай чәй урынын үзе хәзерли, кызып килә торган мичтә берәр таба гына пәрәмәч пешереп алуны, яисә бер-ике таба гына әчегән коймак салып алуны үзенә генә калдыра. Ул шундый эшкә бервакытта да үзенең сабак кызларын кушмый, ул андый нечкә эштә беркемгә дә ышана алмый.

Хәзрәт тә тормышын бер юлдан илтә. Ул, мәчеттән чыгуга, мәдрәсәгә керә. Зуррак шәкертләрнең сабакларын тыңлатып, кечкенәләрнең укыганнарын карап, хәлфәләргә Коръәнне, мәгънәле китапны үзе бирә. Кизүнең кем икәнлеген, иртәгә кемгә утын китерергә нәүбәт икәнлеген, кемгә мәдрәсә бәкесен уярга икәнен үзе тикшерә. Шуннан соң акрын гына өенә юнәлә. Ул, өйгә кергәнче, сыерның азыгы барын-юклыгын күздән кичерә. Өйдә аны һәркөнне бертөсле ачык, һәркөнне бертөсле көтеп, Сәгыйдә каршы ала. Балалар белән маташа-маташа тамагы карылып беткән булса да, аңламый, укымый торган балаларга кычкыра-кычкыра авызы кибеп беткән булса да, аны Вахид һәрвакыт кайнаган самавыр янында көтә торган, яна торган мич алдында табасын кыздыра торган итеп таба. Вахид һәркөнне өенә: «Әссәламегаләйкем!» — дип керә, һәркөнне Сәгыйдә остазбикә: «Вәгаләйкем әссәлам, исәнме, хәзрәт, бик арымадыңмы? Әнә, хәзрәт, җылы су бардыр, битең-башыңны ю, мәдрәсәдә тузанланып беткәнсең, мин берәр таба гына пәрәмәч пешереп алыйм»,—дип каршы ала.

Вахид мулла кулын-башын юа, үзе чәйнекне кыздырып чәйне сала, чәй пешә башлагач та: «Әйдә, Сәгыйдә, чәй өлгерде, ясыйм», — ди. Ләкин Сәгыйдәдән: «Хәзер, хәзрәт, пәрәмәчемнең өсте генә киләсе бар»,—дигәнне

ишетсә дә, «яса, хәзрәт, яса» димәсә, чәйнекне читкә алып, самавырны бастырыбрак куеп көтеп тора.

Вахид хәзрәт чәйне ясагач та, Сәгыйдә остазбикә йә пәрәмәч, йә коймак, йә сумса күтәреп килеп утыра һәм дә һәрвакыт: «Җә, хәзрәт! Исәнме?» — дип тагы бер дәшә.

Икесе дә берсенә берсе карашалар да исәнлекне, түгеллекне аңлашалар. Акыртын гына сөйләп-сөйләп чәй эчә башлыйлар.

Вахид мулла да чәйне ярата, Сәгыйдә остазбикә дә ире сөйгән нәрсәне, әлбәттә, мәкруһ күрми. Пәрәмәч тә тәмле була. Сөйли-сөйли вакыт үтеп киткәне сизелми дә кала.

Ул арада булмый, хәзрәткә бер-бер эш чыга: берсе үлә, берсе туа, берсенең кызы китә, берсе килен ала.

Өйләдән соң күп вакытта хәзрәт бер-бер кешегә мәҗлескә бара.

Абыстай да, кызларның төшке сабакларын үткәреп, мулланы китергән ат белән ашка барып килә.

Кичке ястүдән соң хәзрәт мәдрәсәдә балаларның күңел сабакларын тыңлатканда, Сәгыйдә остазбикә йә бербер нәрсә тегә, йә кунак-төшем килер дип бер-бер аш пешерә, яисә хәзрәт кайтуга мунча хәзерләп куя.

Көннең көнендә тормыш шулай бара, елның язында, көзендә, җәендә, кышында тормыш бер эздән ага...

Абыстай хәзрәттән башка бер эш эшләми, берни капмый.

Хәзрәт абыстайдан башка ашый-эчә алса да, өйрәнмәгәнгәме, тәме булмагангамы, ансыз ашка утырмый.

Никадәр йокысы килсә дә, никадәр арыган булса да, абыстай хәзрәт чишенеп ятмаенча урынга якын килми.

Абыстай: «Ятарга кирәк, хәзрәт!» — димәенчә, хәзрәт тә барып урынга сузылмый.

Ел үткән саен шул тормышның программасы киңәя барса да, төбе-эзе һаман бер кала.

Икенче елда яшь муллаларның атлары була. Өченче елны кунак өйләре арта. Дүртенче ел йорт-тирәләре ширмалар белән корылып, матур бакча утыртыла. Бишенче елда азбарлар мал-туар белән, йорт кош-корт белән, ындыр ашлык, печән белән тула.

Яшь мулла белән яшь остазбикә бөтен көчләре белән мәхәлләгә хезмәт итәләр. Мәхәллә дә бөтен ихлас белән, муллалар мохтаҗлык күрмәсен дип, гошерне, фитырны, гүр садакасын, нәфел садакасын ташый гына бирәләр.

Өч-дүрт ел эчендә Вахид мулла тирә-юньдә игътибарлы муллага әверелә; Сәгыйдә остазбикә атаклы остазбикә булып, бөтен авыл хатынның киңәшчесе, мәслихәтчесе, гакыл бирүчесе, дин-диянәт өйрәтүчесе була. Карт хәзрәтләр, карт абыстайлар элгәре никадәр авырлыклар ясарга тырышсалар да, мәхәллә халкы боларга ауганын күреп, алар да угыллары белән киленнәренең шул «тәүфикъсыз»лыклары белән килешәләр, шуңарга өйрәнәләр.

Һәрнәрсә үз юлында бара. Вакытында хәзер Сәгыйда остазбикә белән Вахид мулла атларын җигеп кунакка баралар; вакытында хатлар язып, атлар җибәреп, кунак китереп, бөтен авылга ямь кертәләр.

Һәр эшне муллаларча эшлиләр, муллаларча кылыналар. Муллаларча кунакка баралар, муллаларча кунак чакыралар, муллаларча гомер үткәрәләр.

Эштән иренмиләр, хезмәттән тартынмыйлар; Алла биргән рәхәт-тынычлыктан ялыкмыйлар.

Көн үткәнен, гомер узганын сизмәенчә дә рәхәтләнеп, берсен-берсе олуглап, кадерләп, берсе өчен икенчесе үләргә хәзер булып, сөешеп гомерне үткәрәләр.

Гомернең яшь вакытында, шау-шу арасында һичбер төрле китеклек күренми; берсенә берсе бөтен дөньяның башка кешеләрен каплый биргәнгә, тормышларында тулмаган бер җир хис ителми.

Өстән генә сөйләгәндә: «Ник баламыз юк икән!» — дигән сүз әйтелсә дә, ул да эч күңелдән кайнап чыгып әйтелми, ул да онытыла, аның юклыгы да бер-берсенең барлыгы белән ябыла.

Яшь мулла белән яшь остазбикәнең гомерләре муллыкта, рәхәттә, тынычлыкта, сөешүдә, кадерләшүдә үтә бара.

***

Капка дөбердәгән кебек булгач, Сәгыйдә остазбикә үзенең сабак кызларыннан бик тиз фонарь күтәртеп йортка чыкты.

Вак кына көзге ягъмур астында, тып-тын караңгы төндә фонарь мелт-мелт итеп оялып кына ялтыраган кебек булса да, бернәрсә күренергә дә ярдәм итмәде. Аларның күзләренә келәт янында жиккән ат тора кебек булды, лапас башында бер көтү малайлар уйнаша кебек тоелды, капка төбендә тирән-тирән упкынлы баз казылган кебек сизелде. Чыккач та кызлар, куркуларыннан бер-берсенә тотыншып, авыз эчләреннән белгән бөтен догаларын укып каттылар.

Сәгыйдә остазбикә батыраеп: «Хәзрәт! Синме?.. Хәзрәт!» — диде.

Иренеп кенә шыбырдый торган ягъмурдагы басынықы һавадан изелеп йоклый торган авыл бер җавап та бирмәде.

Тынылык, коточкыч тынылык бөтен тирә-юньне тутырды.

Фонарь утының төшүе белән, әле анда өч башлы кеше кебек, әле монда озын куллы бозау кебек нәрсәләр куренгәли башлады.

Кызлар: «Абыстай! Куркамыз, куркамыз, куркамыз!» — дип, өйгә таба борылдылар. Сәгыйдә бикә тагы: «Хәзрәт... Хәзрәт!» — дип дәште.

Тагы күктә-җирдә — күктәге фәрештәләр дә, җирдәге җанварлар да аның эндәшүенә җавап кайтармады.

Ул өйгә кергәч тә, эшләре белән кергән кызларның кайсының чигүенә, кайсының тегүенә, кайберсенең корамалар җыюына карап бераз сөйләгән кебек кылынса да, күңелендәге дәртен бастырыр өчен: «Мин тәһарәтем барда намаз укып алыйм, хәзрәт кайтса, фонарь чыгарырга онытмаңыз», — дип, өйнең түрендәге лампаны бераз бастырып, намазлыкка утырды.

Аның исәбе ястүсен уку булса да, күңелендә тулган курку берлән өмет аның бөтен тынчлыгын алганга, ул авыз эченнән генә үзе белгән догаларны укырга кереште. Күңеле никадәр сынык булса да, бөтен тәнен-җанын

бәндәлек, бәндәнең көчсезлеге баскан булса да, аның башыннан: «Ул кая? Ни булды?» — дигән сөаль китмәде.

Чын, ул кая?

Иртәгә, йә аннарыга кайтам дип киткән кешегә дүрт көн булды, һаман юк!

Кайдан собраниесе шул юк кәгазьне тикшерергә йибәрде!

Кайдан ул шундый караңгы төнле, кыска төнле көзге айларда белмәгән-нитмәгөн авылга китеп барды!

Төне нинди? Аты, килеп, күпер астына төшеп батып үлсә... Үлсә?!

Шул сүз аның бөтен тәнен-җанын өшетеп йибәрде. Аның тәнендә ыж иткән бер салкын дулкын үтеп, ул утка әйләнеп, йөрәккә барып капты...

Ул катты да, пеште дә... Тирләде дә, туңды да...

Уй туктады, фикер бетте...

Аның алдында шул вак ягъмурлы, караңгы төнле кичтәге коточсыз шәүлә кебек «Ул үлсә?!» дигән сүз килеп басты.

Әллә нинди кырык куллы, йөз тырнаклы, мең тешле булып, авызыннан ут чәчә торган зобани сурәтенә кереп килеп басты.

Сәгыйдә өнеме, көнеме икәнен онытты. Авызындагы догаларны кызу-кызу укырга, әллә нинди зур бер көчкә тиз-тиз башны бөгәргә, ялынырга-ялварырга кереште.

Ләкин күңеленнән: «Ул үлсә?!» дигән сөаль китмәде. Шул коточкыч сөальгә җавап та таба алмады.

«Чыннан да ул үлсә?.. Авызымнан җил алсын!..» Ул Вахид, шул Вахид хәзрәт, Сәгыйдә белән менә инде сигез ел бербуйдан бергә торган хәзрәт үләме?..

Ул ни дигән сүз?..

Ул мөмкинме?..

Сәгыйдә аннан башка дөньяда тора аламы, яши аламы?..

Бердән аның күңелендә Вахид хәзрәт үлде булып куйды...

Шул вак ягъмурлы караңгы төндә анының ак кәфенеле җәсәде күренгән кебек булды...

Ул, зыяндаш тоткан кебек, калтырап китте.

Бөтен тирә-юньне — өендәге кызларны, йортын-җирен, авылын, кардәш-кабиләсен онытты, һәммәсен онытты...

Һәммәсе бетте...

Теге, төнге караңгы, очы-төбе юк упкынылы караңгы аны каплады, томалады.

Суык, салкын, өметсез, куркынычлы бушлык анының күңелен, йөрәген тутырды.

Анының тешләре тешләренә бәрелеп шакырдарга тотынды...

Бер кыз: «Абыстай! Кайтты бугай!» — дип сикереп төште.

Сәгыйдә, бик куркынычлы ямьсез төшеннән уянып китеп, төш булуына шатланган кебек, фонарьны көтмәенчә дә чыгып китте. Тагы тавыш дөрест чыкмады... Тагы хәзрәт кайтмады...

Сәгыйдә шул ямьсез уйны ташлар өчен кызлардан самавыр куйдырды. «Мөхәммәдия» алып, алар белә парлап укырга кереште. Ләкин «Ул үлсә?» дигән сөаль башыннан китмәде.

«Ул үлсә?.. Минем кемем кала?!»

«Ул бөтенләй миннән югаламы?.. Бөтенләй... Берни калдырмый?..»

«Әй бер угылым булса иде!..» —дип йибәрде.

Шул сүз, шул мәгънә анының бөтен йөрәгенә кереп утырып, аңарда моңача һичбер булмаган бер куәт белән балалы буласы килү — үзенең угылын күрәсе килү дәртен тудырды.

Шул дәрт шулкадәрле куәтле булды, ул «Хәзрәт үлсә?» дигән сөальне дә оныттырды. Вә анының бөтен уен-күңелен шуңарга таба бордырды.

Таң алдында былчыранып-юешләнеп, суга манчылган кебек булып хәзрәт кайткач, беренче сөаль бердән бетсә дә, икенче сөаль куәтләнә генә, ныгый гына барды.

***

Моңарга кадәр дә анасыннан, туталарыннан: «Балагыз гына юк, тормышыңыз бик матур», — дигән сүзне ишеткән булса да, Сәгыйдә аларның мәгънәсен хәзерге кебек аңламаганга, әһәмият бирмәгән иде. Шул мәгълүм кичтән сон шул сүз бөтенеләй икенче төрле мәгънә алганга, шул балалы булу, угылыңны «үт-үт» иттереп сөю дигән сүзләр Сәгыйдәнең бөтен тәне-җанының теләвенә әверелгәнгә, ул кулындагы бөтен көче белән шул уйга ябышты.

Мулла хатыннарыннан сорап, элгәре әллә нинди догалар укырга тотынды.

Кырык көнгә кадәр меңәрдән салаты мөнҗия укыды.

Йиде атнада йиде мәртәбә Коръән хәтем итте.

Унике атнаның баш кичендә, кече атнасында йиде газизгә җиде «Ясин» чыкты.

Үзенең генә көченә, ихласына ышанып җитмәгәнгә, йиде Коръән чыгарга күрше авыл остазбикәсенә йиде бөтен тәңкәсен җибәрде. Үзенең кияү күлмәгене садака бирергә нәзер итте. Өч ел рөҗәб, шәгъбан рузасын тотарга вәгъдә бирде. Аллаһе Тәгалә аның  ялваруына тик калды.

Ул, гөнаһ булса да дип, имчеләргә күренде.

Бер карчыктан чүлмәк салдырды, бер хатыннан сылатты, күрше авылның керәшен хатынннан ырым ясатты. Чуваш хатынннан китергән әллә нинди ырымлы икмәкне бисмилласыз ашады... Әллә нинди бер марҗадан китерелгән, чиркәү шәме тамызган чиркәү суын да эчте...

Алла бирмәде дә бирмәде...

***

Бала сагыну белән өметсезлектөн мөрәккәб бер хис Сәгыйдәнең йөзендә әллә нинди бер кайгылы сызык сызды, шул китеклек аның тавышына мескенелек мәдден кушты, аның кыяфәтенә әллә нинди разый түгеллек буявын бизәкләде.

Аның табигате йомшарды, изрәде. Ул, сабак белмәгән кызларны чаж-чаж чыбык белән пешерә торган абыстай, бөтен кызларга «ай гакыллым, кызым» дип дәшә торган булды; аның сүзендә, сөйләшүендә әллә никадәр йомшак сүзләр күбәйде. Авыл хатыннарына: «Канатым, абыстаем!» дип сүзләргә башлаган кебек, кош-кортларга, мал-туарга да сөюле атлар кушты. Тавыкларга «тавыккаем» дип, чебешләргә «чебешкәем» дип дәшүгә башка, өстләрен мамыклы җон гөнаһсыз иттереп каплаган чебешләрне кулына алып, авызына китереп сөя торган булды.

Сыерны сауганда ул һичбер вакытта аның белән сөйләүдән туктамады; ул аның мөңрәп каршы алуына каршы: «Кая, кил, кил, әй акбашкаем? Ә... Сөтең тулдымыни?.. Кил менә, йиңеләерсең, аннары күшәп ятарсың», — дип башламаенча калмады.

Чуар бозауга умач эчергәндә ул аның йоннарын сыйпады, сылады, аның ахмак күзләрендә әллә ни аңлаган кебек: «Тагы эчәсең киләме? Юк инде, йитте... Йитте, хуш иңде», — дия торган булды.

Бер-бер кардәш-кабилә кунакка килсә, ул бөтен гомерен шуларның баласы артыннан йөрергә сарыф итте: ул үзе йоклатты, үзе коендырды, үзе уйнатты, сөяргә тотыныса, баланы елатмаенча туктамады.

Элгәре һич әһәмият бирми торган хатын, ул, хәзер бөтен кардәш-кабиләнең баласының исемен-яшен белде. Бөтен дуст-иш хатынының кайчан бала табачагын хисаплап торды. Буш вакытын шуларның угылларына кәләпүшләр чигүгә, кызларына күлмәкләр, алъяпмалар ясау белән тутыра башлады.

Элгәре Вахид хәзрәт Сәгыйдәнең шул сагышына каршы читтәрәк торган кебек күренсә дә, бик тиздән ул да үзенең күңелендәге балага сагынуны шуңарга кушты. Ике дәрт бергә кушылгач, тагы киңәеп китеп, тагы тирәнәйде. Шәһәргә бардымы, Вахид хәзрәт Сәгыйдәнең авыл тулган балаларына: «Балалар күлмәклеге бармы? Балалар кәләпүше бармы? Балалар уенчыгы бармы?» — дип, базардан эзләп бүләкләр ташый башлады. Бәйрәм алдында, атына утырып базарга барып, әллә никадәр бүләк-салак алып кайтучан булды.

Кайчакларда алар, балалары булуын уйлап, шуның хыял диңгезендә сәгатьләрен, көннәрен уздырдылар. Алар, булган балалары сырхаулаган, үлем алдыннан хисаплап, көннәрен, төннәрен йокысыз кичерделәр.

Шул уй, шул һәркөнне иртәдән алып кичкә кадәр күз алдыннан китми торган сагыш һәм дә уртак сагыш боларны тагы якынылатты, берсенә берсенең кыйммәтен тагы зурайтты.

Инде икәүләп бала булдыру дарусын эзләргә керештеләр. Сәгыйдә үзенең бөтен кылганнарын, хәтта чиркәү суы эчүенә кадәр, мулласына сөйләде. Вахид хәзрәт тә үзенең фельдшерлар, докторлар, ишаннарның барысыннан да мәдәд эстәгәнен ачты. Һәммәсеннән дә нәтиҗә бер булса да, Алланың рәхмәте киң дип, тагы тотындылар.

Икәүләп Хуҗалар өстенә барып корбан чалдылар, икәүләп барып Мулламорад бабайның чишмәсеннән алып кайткан су белән тәһарәтләнеп Коръән чыктылар. Икәүләп, Чәһарьяр гыйзам рухына багышлап йиде көн руза да тоттылар...

Шул тынчсызлык боларда балага мәхәббәтне, дәртне тагы арттырса да, үзләрен арытты, ялыктырды. Икесендә дә әллә нинди зәгыйфьләнү, өметсезлек куәтләнде.

Менә беркөнне Сәгыйдәнең бер тутасы кияве, балалары белән килеп төште. Сәгыйдә кунакларның үзләреннән битәр, балаларын кадерләде.

Мулла җизнәләре әллә никадәр уенчык алып кайтты, апалары һәммәсенә яңа күлмәкләр, яңа кәләпүшләр кигезде. Аш вакыты булдымы, үзе утыртып, үзе ашатты, кич булдымы, үзе яткырды.

Мулла җизнәләре дә зурракларының кулларыннан тотып ындырга алып барды; бакчага кертеп, аларга агачларны, гөлләрне күрсәтте; алар белән үзе уйнарга да утырды. Хосусән, дүрт яшьлек Әхмәт исемле бер бала аларның икесенең дә бөтен дикъкатьләрен тартты. Алар, кунакларны җибәрмәскә теләп, кыстап йөдәп беттеләр. «Балаларны калдырыңыз», — дип сорарга тотындылар. Күп балалы баҗа белән тута Әхмәтне калдырырга, өйрәнсә, үзләренә дә бирергә булдылар һәм дә Әхмәтне калдырып та киттеләр.

Сәгыйдә остазбикә Әхмәткә хәзер үк әллә ничә күлмәк-ыштан текте. Мәрфуга әбидән бик тиз хәзрәттән калган әдрәстән казаки да тектерде.

Мулла җизнәсе, шәһәргә барып, аңарга әллә никадәр уенчыклар өстенә читек-кәвеш, ялган сәгать тә алып кайтты.

Әхмәтнең кесәсеннән кәнфит, йимеш, чәкчәге өзелмәде; берсеннән берсе кызык уенчыклар, тәтиләр алдында бетеп тормады.

Аны бергә яткырдылар. Бергә йөрттеләр, бергә сөйделәр. Ләкин Әхмәт, әллә нигә көннән-көн күңелсезләнде; ул тик торганда еларга тотынды; бара-тора көне-төне акырырга башлады.

Аны уенчык та кызыктырмады, тәмле кәнфитләр да куандырмады, апасы, җизнәсенең йомшак сөюләре дә тынычландырмады.

Бала көн акырды, төн акырды.

Вахид хәзрәт өшкерде, бөти язып такты — файда булмады.

Сәгыйдә бикә мунча ягып юындырды, тирләтте — файда чыкмады.

Ахырдан эчләре бозылып, авызларыннан селәгәйләре агып, тәмам авырырга тотынды.

Сәгыйдә белән Вахид хәзрәт, кеше баласын үтерәмез дип, котлары очты. Вахид хәзрәт төнлә белән ат җигеп, исән вакытта Әхмәтне илтә китте. Сәгыйдә Әхмәттән калган уенчыклар, әйберләр, ваткан чынаяклар янында бик озак утырып елады.

Хәзрәтләрнең бала алырга теләүләре әллә кайдан чыгып өлгергәнгә, төрле йирдән балалар әйтә башладылар. Беркөнне бер хатын матур гына кара кашлы, биш-алты яшьлек бер малай тотып килеп керде. Сәгыйдәгә: «Абыстай! Йортларымызны карарга кайткан идем. Ирем авырды дип хат алдым. Балаларымыз, Аллага шөкер, йитәрлек. Шул угылымызны тәрбиягә алсаңыз ла. Үзе гакыллы, үзе үткен. Теләсәңез, бөтенеләй сезгә бирермез», — диде.

Хәзрәт тә, Сәгыйдә остазбикә дә малайны бик ягымлы тапкач, калдырырга булдылар. Малай бик тиз өйгә ияләште. Бик тиз тазарып китте.

Чиккән кәләпүш, кызыл төймәле казаки, аягына читек киеп, малай бик тиз мулла баласына охшады.

Сәгыйдә тагы аны юындырырга, киендерергә, ашатырга, эчертергә бөтен вакытын сарыф иткән кебек, хәзрәт тә аңарга уенчыклар китерергә, телдән генә догалар өйрәтергә бөтен көчен сарыф итте.

Бала көннән-көн матураеп, үсеп килгәндә, көннән-көн боларның мәхәббәтләрен җәлеп итә барганда, абыстайның бер йөзеге югалды. Ул, шулай, зур мәсьәлә булмаенча үтсә дә, бераздан тагы беләзеге югалгач, күрше килен Маһруйдан шикләнә башладылар.

Тагы бераздан соң хәзрәтнең кесәсеннән акчасы югалды.

Берникадәрдән сон күрше хатын абыстайга, акыртын гына иттереп, угыллары кибеткә йомырка илткәнен сөйләде.

Икесе дә Вагыйзне шул гадәттән биздерер өчен кыш буе тырыштылар, тырмаштылар. Ләкин көн үткән саен ул гадәт аңарда шәбәя барды.

Өйдәге әйберләрне бикләмәенчә йөрү мөшкелләште.

Икенче елны теге хатынга, кайтуы белән, Вагыйзне кире бирделәр.

Вагыйз киткәч, хәзрәт белән остазбикәнең тормышы тагы буш булып калды.

Ул тагы үзенең мәгънәсен, кирәклеген югалтты...

Тагы аларның икесен дә өметсезлек басты.

***

Идел буеның көзләрендә бер-ике атна кояшлы матур көннәр була.

Көзнең сазы, ягъмуры алдындагы бу көннәр үзләре аяз була, үзләре кояшлы була.

Һавада әллә нинди, тел белән әйтеп бетерерлек түгел бер ис була. Авылларда шул көннәрдә кабак исе, пешкән шалкан исе һәр истән өстә торса да, шуларга башка, тагы әллә нинди яңы икмәк, яңы салам исе диимме, әллә шуңар га кушылган, базардан китерелгән яңы күлмәклек, яңы чалбарлык исе диимме, бер ис тулып тора; тагы дөрест булмады: ул тулып, авылны аңкытып тормый, гает көнендә муллалар йортында гатырша мае исе кебек, туйлы йорттагы чәкчәк, катлама исе кебек бөтен исләрне басып та тормый.

Ләкин ул, күренмәгән, сизелмәгән көенчә, борыннан яшерелеп, бөтен авылның өстендә падишаһлык сөрә...

Бөтен авылның өстенә үзенең шул яшерен-гизле исен сибеп тота.

Шәһәрләрдә дә бу ис бөтен тормышның өстендә торса да, ул монда алма, карбыз, кавын исенә буялып сизелә, ул монда тагы нечкәрәк иттереп хөкемен йөртә. Тагы матуррак хис калдыра, тормышны тагы бизәклерәк, тагы төрлерәк, тагы татлырак, тагы тәмлерәк иттереп күрсәтә. Кыска гына әйтергә сүз табып булмаганга, язып аңлатырга көч җитмәгәнгә, бу иске —туклык, байлык, барлык исе генә диик лә...

Кояшның йөрешеңдәме, җылысын чәчүендәме, әллә йирне каплаган яшелләвекләрнең, яшел уҗымнарның, саргая башлаган яфракларның шул нурны каршы алуларында — ингыйкас иттерүләрендәме, җәйдә дә, көздә дә, язда да күрелмәгән бер башкалык була; була гына түгел, бөтен шул көннәр шул йомшак башкалыкка манчылган, җумайланылган була. Болыннарны, яланнарны, суларны, урманнарны коендыра торган кояшның нуры тагы аграк, тагы яктырак була.

Суынып килә торган йирдәге яшелләвекләр, үләннәр, уҗымнарны кояшның сөюе, үбүе тагы җылырак була.

Яңа казаки киеп урамга чыккан егеткә, яңа күлмәк киеп суга бара торган кызга да кояшның карашы тагы мәхәббәтлерәк, тагы моңлырак була.

Бөтен йир, бөтен үсемлекләр, бөтен хайваннар шул кояшның нуры астында бер тынчлык сизәләрме — аларның да һәммәсендә тавышсыз-туышсыз бер хәят тоела.

Кошы-кортының тартышырга эше беткәнгә, чар-чор килүен бөтенләй оныткан да тик кенә кояшта җылына, коена.

Сарыгы, сыеры, кәҗәсе дә гаилә мәшәкатен, баласын югалту, анасыннан адашуларны бөтенеләй хәтереннән чыгаргангамы, ул да акырмый-бакырмый, һаваланып кына сузылып ята.

Авылның өйләре, моннан бер-ике атна элек «уу» килгән, дулаган өйләре дә һәммәсе тынычлыкка баткан.

Бөтен йир — тын; бөтен тормыш — бөтен. Бөтен тирә-юнь — тук.

Ләкин бу тынлыкта әллә нинди моңлык бар. Аңлап бетерерлек түгел бер моңлык бар.

Кояшның шул үтә күренә торган яктылыгындамы, кояшның җылысын бөтен дөньяга тигез йиткерер өчен тырышуында, нурын яудыруындамы, әллә шул чиксез тын, ак көндә һаваланып кына агып йөри торган нечкә-нечкә күбәләк җепләрендә, үрмәкүч дилбегәләрендәме, бер бәхилләшү, бер аерылышу, бер кызганышу буявы, бизәге бар.

Авылларда бу вакытта киленнәр, каенаналар да орышышмый.

Бу вакытта авылда берсен берсе күрә алмый торган яшь әтәчләр дә канга батышып сугышка керешми.

Бу вакытта мулла белән мөәззин дә фидия өчен, зиярәт печәне өчен кычкырышмый, талашмый.

Әллә ник һәрнәрсә, һәр мөнәсәбәт тынып тора, дустлык, дошманлык тик хәл җыя.

Бу көннәрне авылда әбиләр атнасы диләр.

Кояшның җылыткан җылысы никадәр ихластан булса да, агачларны яфракландырырга, гөлләрне чәчәкләндерергә көче җитмәгәнгәме, кояшның нуры никадәр матур, никадәр йомшак булса да, сандугачның йөрәгенең ут каба торган почмагын кабызып җибәреп, аны үзен, тирә-юнен оныттырып сайрау-җырлауга чумдыра алырлык чаткысы булмагангамы, әллә башка бер сәбәптәнме — бу көннәрнең җылысын карчыклар җылысына, бу көннәрнең матурлыгын карчыклар гүзәллегенә охшатканнар.

Менә шундый карчыклар атнасы кергәч тә, авыл халкы арасында кыз сорау, угыл өйләндерү башлана.

Шул карчыклар көне җиткәч тә муллалар арасында кунакка бару, кунак чакыру дәвере керә.

Муллалар бер-берсе белән күрешеп сыйлашулар, иртәдән алып кичкә кадәр ашка йөрешеп, кичке озын төннәрдә остазбикә белән мунчадан соң яңы

бал белән, Василийдән алган яңы чәйне унар-унбишәр чынаяк кына эчүләр, тәмләп утырышулар башлана.

Монда муллалар бер-берсенә хисап бирешәләр.

Гошернең күпмелеген, үлем-җитемнең ни дәрәҗәлеген, киләчәк туйларның ни төрлерәк булуы хакында сөйлиләр, уйлыйлар.

Мәктәп, мәдрәсә мәсьәләсе, киләсе рамазанның башы шинбәдәнме, якшәнбедәнме, дүшәнбедәнме, әллә сишәнбедән үкме башлауларын төшенәләр. Иске моназарә хәлләрен хәтерләп, моназарә дә кылышып алалар.

Үзләре сизмәенчә генә, үзләре белмәенчә генә, мәхәлләне алып бару, халык белән мөнәсәбәтне йөртүләрнең юлларын уйлыйлар, сөйлиләр, маяклар утырталар.

Остазбикәләр җыелышы, әлбәттә, үзгәчәрәк була.

Алар бүлмәдә хәзрәтләрнең сөйләгәннәрен тыңлап утыргаласалар да, күп вакытта, мөәззин Мәрфугасының затсызлыгын, иптәш мулланың остазбикәсенең төрки китабыннан вәгазь әйтүен сөйләгәндә, хәзрәтләрен онытып та җибәрәләр. Үзләренең дөньяларына чумып, үз шатлыклары, кайгыларында коеналар, йөзәләр.

Теге якта ай башы, мәдрәсә мәсьәләсе хәл ителсә, бу якта кызлар бирү, угыл өйләндерү, шәкерт угылын укыту мәсьәләләре чишелә.

Бөтен кыш буе муллаларның түрендә дә, бүлмәсендә дә шуларның татбикаты гамәлгә куела.

Менә бу елны да шулай булды. Менә бу елда да хәзрәтләр остазбикәләре белән кунакка чакырылдылар.

Иттифакый быел, шактый гына бай бер кеше угылын өйләндергәнгә, шәһәргә чакырылдылар.

Сәгыйдә остазбикә белән Вахид барып кергәндә, бөтен тирә-юньнең мулласы җыелган кебек, мондый муллалар мәҗлесендә сирәк очрый торган Казан сәүдәгәрләреннән Фәхри хаҗи да җәмәгате берлә бар иде.

Кунаклар күп булганга, парлап-парлап яткырырга урын табарга мөмкин булмаганга, никадәр оят булса да, ирләр аерым, хатыннарны аерым яткырырга тугры килде.

Муллалар, мөдәррисләргә бу үзгәреш күңелле дә булды.

Аларга шул ятыш-торыш мәдрәсәне хәтерләтте.

Төн буе алар берсен берсе бүлеп, мәдрәсә хатирәләрен яңарттылар.

Картлары да, яшьләре дә, шул хикәяләр астында үзләренең михраб сахибләре икәнлекләрен дә онытып, гади очрашуда сөйләнмәслек хикәяләр, хатирәләр дә сөйләштеләр.

Абыстайларның артларында мәдрәсә кебек берләштерә торган бер хатирә булмаганга, «Дөррелмәжалис», «Дөррәтеннасыйхин»нан вәгазь сөйләү, кадер кичләрдә «Мөхәммәдия» уку, үлек юу бик бертөрле, төссез булганга, алар бик тиз бала-чагага күчтеләр.

Беренче көнне үк бөтен остазбикәләр үзләренең угыллары, кызлары хакында озын хисаплар биреп өлгерүгә башка, килеш-йөрешләре, табигатьләре белән таныштырып өлгерделәр.

Биреләчәк кызларның җиһазлары, матурлыклары, уңганлыклары хакындагы сүзләр дә, икенче көнне бетерә алмаганга, Сәгыйдә бикәнең баласызлык мәсьәләсе дә килеп чыкты. Беренче күрешә торган остазбикәләр шуның бөтен ягы берлә таныштылар. Иске танышлар яңадан-яңа дарулар, яңы догалар, яңы тылсымнар өйрәттеләр, яңы фикерләр, яңы хикәяләр сөйләделәр.

Сәгыйдә, боларны сөйли-тыңлый башы катып беткәнгә, боларның һәммәсеннән дә һичбер төрле өмете булмаганга, әбиләр хикәясе кебек кенә тыңлады, һәммәсенә рәхмәт укыды.

Һичберсенең сүзен тотарга дип башында кечкенә генә дә теләү кузгалмады.

Менә төн булды. Ятарга урыннар җәелде. Сәгыйдә, шул, балалары хакында туктамый сөйләп торган хатыннарга үзенең ятлыгын хис иттеме, почмакка гына, зур гөл астында үзенә урын салды.

Ләкин ул ятарга өлгермәде, Казан хатыны Үлмәс абыстай: «Мин дә, остазбикә, яныңа ятыйм»,—диде.

Сәгыйденең ялгыз каласы бик килсә дә, шул аз сөйли торган хатынның әллә кай бер җиреннән курыкса да, кирәкми дия алмады.

Үлмәс остазбикә янына урын салды.

Озак үтмәде, көн буе ашта йөреп арыган остазбикәләр тирән-тирән йокыга киттеләр.

Ашказаннары барысының да шактый авыр булганга, төрлесе төрле нечкәлектә, төрле озынылыкта мышнарга, мырылдарга керештеләр.

Көйле-көйсез мышнау, мырылдау, хырылдау берлән өй тулды.

Бүлмәнең диварларына эленгән остазбикәләрнең күлмәкләре, төнге кечкенә лампаның караңгы шәүләләренә кушылып, кайсылары юан-юан кешеләр кыяфәтен, кайсылары өеп куйган печән сурәтен алдылар.

Зур гөлләр, яфраклары сары дисәң сары түгел, ак дисәң ак түгел төс алып, тагы зурайдылар, киңәйделәр.

Шкафлардагы чынаяк, чәйнекләрнең әллә кай бер җирләре ялтырап калып, сүнә торган лампа кебек мелт-мелт итеп күзләрен кысыштылар.

Кайсылары караңгы төндәге кара мәче күзе кебек бер җиргә текәлделәр. Шул йирне ашарга, йотарга теләгән кебек, шул йиргә кадалдылар, караган саен аларның утлары зурая барды; караган саен аларның утлы күзләренең йөрәккә җибәрә торган уклары тирәнәя барды.

Мыш-мыш йоклау арасында остазбикәләрнең әйләнүләреннән чыккан тавыш, ара-тирә бер-берсенең авыр төш күргәндә әйтеп йибәргән сүзләре, куркып кычкырып җибәрүләре, теге күлмәкләрдән чыккан кебек сизелеп китеп, курку-шикләнү тудырды.

Сәгыйдә бикә, «Бисмиллаһи әлләзи» әйтеп күзен йомса да, әллә нинди догалар укып йокыга китәргә теләсә дә, һаман булдыра алмады. Уй, әллә нинди уй, баштан китмәде.

Ул кайвакыт йоклау берлән йокламау чигенә барып җиткәндә генә, бер-бер остазбикәнең озын иттереп хырылдап җибәрүе берлән уянды.

Кайвакыт йоклап киттем дигәндә генә аның күзенә ташланган әллә нинди ямьсез бер сурәт аны куркытып күзен ачтырды.

Ул әйләнде, сузылды, төрлечә ятып карады, йокыга китә алмады.

Акрын гына кулына таянып, яртылый утырып, тирә-юньне карамакчы, шунда бер дә ят нәрсә юклыгын күзе берлән күреп, күңелен тынчландырмакчы булды.

Бердән күзе күршесендәге Үлмәснең ялтырап ачылып ята торган күзенә очрады.

Сәгыйдә үзендә шуның киңәеп җәйрәп, ит тушы кебек яткан таза тәненә каршы дошманлыкмы, җирәнүме хисе туганын белергә өлгермәде, ул: «Остазбикә, йокламыйсыңмыни?» — диде.

Аның тавышында, шул сүзләрне әйтүендә Сәгыйдә әллә нинди бер көч, бер ямьсез көч сизде. Аның башында: менә ул шундый бер йирдә, шундый бер тирә-юньдә, шундый моңлы караңгылыкта шул тавышны ишеткән иде, шул тавыштан курыккан иде кебек булды. Кая ишеткәнен табып өлгерә алмады, аның тәнендә бер калтырау, курку калтыравы үтте.

Ул бердән шул тавышны тапты. Әйе, ул аны ишеткән иде.

Кечкенә вакытта түбән очтан кунарга килгән Латыйфа әби сөйләгән әкияттә ишеткән иде.

Ул әнә теге, матур кызларны пешереп ашар өчен чикләвек ашатып симертә торган пәри карчыгының тавышы иде.

Аның йомшаклыгы шул пәри карчыгының хәйләле йомшаклыгы иде.

Ул бердән хәзрәтен искә төшерде. Аның күңелендә хәзер, хәзер менә шул куркынычлы тавыштан, шул коточкыч пәри утлары ялтыраудан хәзрәтенә сыгынасы килү уе туды.

Шул уй фикерен, бөтен башын каплады, томалады.

Ул, бисмилласын әйтеп, уянып киткән кебек булып, тагы Үлмәскә карады. Аның ике күзе тагы тирәнрәк, төпсезрәк күренде. Аның шул упкыннарында әллә ниләр яшеренә кебек хис ителде.

Ул шул куркуны бетерер өчен: «Юк ла, юкка шикләнәм, бу бит — Үлмәс абыстай. Менә аяк очымда Шаһид мулла хатыны, әнә теге мерелди торган — Исхак мулла остазбикәсе, менә бу — мин», — диде.

Озак җавапсыз тоту булмасын өчен: «Син дә йокламыйсыңмыни?» — диде. «Юк. Мин ялгыз ятарга өйрәнмәгән. Сөймим,» — диде.

Сәгыйдә шул сүзләрнең әйтелүендә яңа бер мәдд тойды, аның күзендә тагы яңа бер сызык күрде.

Аның елмаюы күзенә тагы бер ялтырау — туя белмәү, капйотлык ялтыравы арттырды.

Ул үзенең юкә агачтан чыккан кебек йомшак, дорфа тавышы белән: «Мин, остазбикә, ирләрне яратам...» — диде.

Сәгыйдә: «Бик яхшы, бик яхшы, иреңне сөю — китап кушкан эш... фәлән»,—дип китмәкче булды.

Үлмәс: «Юк, остазбикә, син әйткәнчә түгел, менә бу ирем минем — өченчесе... Мин аңарга хатынын аертып чыктым. Ике баласы бар иде. Үземнең дә иремдә бер кызым калды. Менә хәзер бу иремнән туйдым. Бәлки, аның белән бу килешем актыгыдыр», — диде дә, нинди тәэсир калдырганын белер өчен, Сәгыйдәгә сөзеп карады.

Шуннан ул акыртын гына тавыш белән өч ир арасындагы аермаларны сөйләргә тотынды. Сәгыйдә гомерендә ишетмәгән сүзләрне, ир белән хатын тормышындагы тәфсыйлатны иң вакларына кадәр ишетте.

Шул хатынның оятсызлыгы аны ачуландырса да, аның әллә нинди бер хисен мыскыл итсә дә, тегенең хикәядән хикәягә күчеп сөйләвенә үзе дә чумып китте.

Хикәяләр беткән кебек булгач, Үлмәс, Сәгыйдәгә карап: «Сезнең, остазбикә, балаңыз булмый... Хәзрәтеңнәнме, синнәнме?..»—диде.

Ул ике күзен тагы Сәгыйдәгә текәде.

Теге чикләвек ашата торган пәри карчыгының «симергәнме, түгелме» дип карагандагы кебек иттереп җентекләргә кереште.

Сәгыйдә кызарды, бүртенде. Шул сөальне шул былчырак хатынның бирүенә хурланды.

Хәзрәтен мыскыллау кебек, үзен ваксыту кебек бер хис астында калды.

Ләкин тегенең күзләренең, иң гади сүз сөйләгән кебек, тик торуы аны тагы чуалтты.

Ул аптырап кына: «Алладан», — диде.

Үлмәс бераз елмаеп, тик кенә остазбикәгә карап торды да: «Менә мин Казанда фәлән байның хатынын беләм. Ире берлән бик яхшы торалар иде. Балалары юк иде. Ләкин Хаҗи — без аны Хаҗи дип йөртәмез, исеме Шәрәфи хаҗи — шул бик кызу кеше иде. Ачуы килсә, ни әйткәнен, ни салганын белми иде.

Беркөнне кайтып керсә, хатын Сәлимә абыстайның приказчиклары белән сөйләп торганын күргән. Сорау-нитү юк, «Талак! Талак!» димәсенме?

Ахырдан приказчикның Шәрәфи абзый үзе йибәргән йомыш белән килгәне дә мәгълүм булган. Ләкин эш эштән үткән.

Менә никях яңартмакчы була. Талак өч булган икән. Сәлимә абыстай да китәргә бер дә теләми.

Хәзрәт: «Ике өйдә торыңыз! Гыйддәтеңез тулгач, бер кешегә кияүгә биреп алмаенча никях яңартылмый», — ди.

Шәрәфи хаҗи бик хурланучан иде. Ни эшлисең?

Ахырдан, менә, яшереп кенә, халык арасына чыкмасын дип, мәдрәсәдәге суфи белән тәхәллел ясыйлар.

Сәлимә абыстайга яңыдан Шәрәфи хаҗига никях укыйлар. Алты-җиде ай үтми, балалары туа... Шәрәфи абзыйга Аллаһе Тәгалә бер угыл багышлый».

Шул сүзне әйткәч, Үлмәс тамак эченнән көләргә тотынды. Ул шундый тәмле-тәмле иттереп көлде; көлде дә туктады, тагы Сәгыйдәгә карап алды да, тагы көлде.

Сәгыйдә аптырап китте. Ни әйтергә белмәенчә, эченнән: «Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла!» — диде.

Үлмәс: «Менә, тагы, безнең авылда бер кешенең баласы булмый иде. Бервакытны кием тегәргә тегүче керттеләр. Шуннан соң Аллаһе Тәгалә бер кыз багышлады...»—диде.

Тагы шуның төсле әллә никадәр хикәяләр сөйләде, һәммәсе соңында бик тәмле иттереп, бик рәхәтләнеп көлде. Бер туктады да, авызында тәме тагы бетмәгән кебек иттереп, тагы көлде.

Бераз туктап Сәгыйдәгә карап торганның соңында: «Менә, остазбикә! Бала күрәсең килсә, насыйп булса, Казанга бар. Үземә кунак булып төш. Һәммә эшендә ярдәм итәрмен. Ирнең үгие юк ул, остазбикә!» — диде.

Шул сүзне ул тавышын зурайтыбрак әйттеме, шул фикер үзенең ятлыгы белән аерыныкы төстә чыктымы, шул җөмләләр чыңлап китте.

Шуларның мәгънәсе шул караңгы сыман бөтен өйне тутырды.

Шул сүзләр Үлмәснең бөтен хикәяләрен онyттырып, барысының да урынына үзе генә басты.

Сәгыйдәнең бала эзләүдә кылган бөтен мәшәкатьләрен, чиккән зәхмәтләрен һәммәсен бердән оныттырып, шул «ирнең үгие юк» һәммәсен томалады, каплады.

Ул үзе аңламаенча гына: «Ирнең үгие юк!» — дип куйды.

Шул сүзнең ямьсезлегеннән коты очып, тәнен калтырау алды.

Тешләре шакылдый башлады.

Башы, зур бер нәрсә белән кинәттән суккан кебек, авыртырга тотынды.

Ул тавышын күтәрә төшеп: «Син ни сөйлисең? Әстәгьфирулла, әстәгьфирулла, авызыңнан йил алгыры!» — диде.

Бөтен тәне-җаны әллә нинди суыкка чумганга, ул калтырана-калтырана йомарланып ятты.

Бик озак белгән догаларын, аятьләрен укыды. Бик озак эченнән шул сүзләрне ишеткән өчен тәүбә итте.Ләкин күңелендә шул сүзләр әллә нинди бер тап калдырганга, майлы, китми торган тап калдырганга, ул эченнән тынычлык таба алмады.

Догалар, элгәреге вакытта аңарга рәхәт, тынычлык бирә торган догалар да һаман шул тавышның барлыгын хис иттерә килделәр.

Менә ул йокыга киттеме, әллә юкмы?

Зур гына су буе. Әллә никадәр ирләр, хатыннар. Һәммәсе бәбәй туена җыелганнар. Кемнең бәбәе икәнен рәтләп белми. Әй... Сәгыйдәнең үзенеке икән... Менә бәбәйгә исем кушар өчен азан әйтәләр, имеш... Мәсҗед манарасыннан әйтәләр, имеш... Менә мөәззин булып теге Үлмәс менде, имеш тә... Кичәге көлүе белән бергә кушып, манарадан: «Ирнең үгие юк!.. Ирнең үгие юуук!..» — дип кычкыра имеш... Шунысы гаҗәп: шул азанга бөтен ирләр, хатыннар кул күтәрделәр дә дога кылалар, имеш!

Менә зурайды, әллә кайдан бер суфи килде имеш... Аның бите шадра, киеме сәләмә, кыяфәте куркыныч имеш...

Ул менә зурая бара, имеш... Ул менә Сәгыйдәгә таба килә бара, имеш. Менә шундагы кешеләр һәммәсе — ире-хатыны, карчыгы Сәгыйдәне тотмакчы булалар, имеш, суфи Сәгыйдәне алмакчы, әллә кая, дию-пәри оясына алып бармакчы, имеш...

Менә ул зурайды.

Менә аның сукыр күзе ялтырый башлады; менә аның кулы Сәгыйдәгә таба сузылды...

Әстәгъфирулла! — бер генә түгел, йөз, мең...

Сәгыйдә качмакчы булды, йөгерде, чапты... Урыныннан кузгалмады!

Менә ул тотты, үзенең кырык кулы белән тотты, Сәгыйдәнең тәнен генә түгел, әллә ничек, бармакларын тән эченә җибәреп, сөякләрдән, тамырлардан тотты.

Ул, Сәгыйдәне үпмәкчеме, йотмакчымы булып, авызын — зур чәүкә баласының авызы кебек авызын якын китерде. Әллә кайдан чыга торган тавыш белән: «Ирнең үгие юк!..» —дип кычкырды.

Сәгыйдә шундагы хатыннар, ирләрдән мәдәд сорамакчы булды. Күзенә: күзләре ялтыраган, авызы ыржайган Үлмәс килеп басты. Сәгыйдә,

бөтен көче-куәте белән котылмакчы булып, селкенде. Тагы китә алмагач: «Хәзрәт!» — дип кычкырып җибәрде.

Ул уянып китте.

Бик озак, куркуын бетерер өчен, догалар укыды. Эченнән тәүбәләр итте. Ләкин шул арусызлык аның белән генә бетмәгән кебек тоелганга, шул тап төшендәге суфиның куллары берлә эчкә керде иттереп хис иткәнгә, акыртын гына торып тышка чыгып, салкын су белән баштан башлап тәһарәт алды. Акыртын гына кереп, шул ук ут яктысында, шул мышнау, хырылдау, шул ук лачт итеп җәелеп яткан Үлмәс янында намазга кереште.

Вакытның кай чак икәнен белмәгәнгә, ул элгәре ике рәкәгать нәфел укыды; аннан тагы дүрт рәкәгать укыды; аннан тагы берничә «Колһуалла» кушып икене укыды.

Намазлыкка утырып, «Ясин»нан башлап белгән бөтен Корьәннәрен укыды.

Кул күтәреп дога кыла башлаганда аның башына бердән:

«Хатынның үгие бармы?» — дигән фикер төште.

«Чыннан да хәзрәткә бер хатын алып бирсәм?.. Аның баласы бит хәзрәт баласы була. Хәзрәт баласы бит минем балам...»— дип уйлады һәм дә шулай җиңел генә була кебек тә тоелды.

Ләкин дога кылып бетереп тагы башын мендәргә куйгач та уй башкаланды.

«Хәзрәткә хатын алып бирү?.. Ул хәзрәт белән булырмы? Миңа «Сәгыйдә» дип тора торган, миңа эндәшә торган, минем белән генә сөйләшә торган, киңәшә торган хәзрәт тагы «Әсма» дия башлармы? Икемезнең арамызга әллә нинди ят, сөйкемсез бер хатын кереп басармы?..»

Ул салкын су сипкән кебек булып китте.

Шул ике, бергә-бергә үскән, бер кеше кебек, бер фикер, бер өйдә яшәгән ике җанлы кеше арасына, берсеннән башка берсе яши алмый торган Сәгыйдә берлән хәзрәт арасына бик зур, ят, чи бер ат тушы китереп салынган кебек булды!..

Ул шул чи, җансыз туштан җирәнде, чиркәнде...

Шул тушның теге ягында калган хәзрәтен, моның матур сүзенә мохтаҗ хәзрәтен кызганды, айады.

«Юк! Мәңгегә булачак түгел!» — диде.

Шул уй берлән ул тагы калгып китте.

***

Иртә белән чәйгә утыргач та тагы шул уй башка төшеп, Сәгыйдәне куркытып йибәрде.

Кичкә таба, муллалар китеп бетеп, Вахид кына калгач та, «Исәнме, хәзрәт» дип кергәч тә, Сәгыйденең башына шул фикер килеп капты.

Ул нигәдер кызарып китте, хәзрәтен бик озак карап аптырап торды.

Вахид мулланың: «Син әллә авырыймсың? Әллә нишләп агарып киткәнсең?» — дигән сөале Сәгыйдәне тагы шул уйга кайтарды.

Ул: «Юк, хәзрәт!» — дип көлемсерәбрәк җавап бирсә дә, теге Үлмәс хатын, теге ямьсез төш аның күңеленә килеп төшкәнгә: «Күршемдә бик юньсез бер хатын бар, шул әллә ниләр сөйләп йокымны калдырды... Ул менә, хәзрәт, оятсыз... әйтеп бетерерлек түгел...»— диде.

Шул сүзләр аның алдында тагы кичәге хикәяләрне, төнге төшләрне җанландыргангa, Сәгыйдә тагы үзендә бер тап барлыкны хис итте. Шул «тап»ны менә хәзрәт күрә торгандыр, шуның әллә нинди бер исе бардыр да шуны хәзрәт сизә торгандыр кебек булды.

Ул әллә нишләп аптырап калды.

Хәзрәтнең: «Әллә бер-бер сүз бармы?.. Фәлән...» — дип икеләнеп соравы аны тагы куркытты. Ул: «Юк, юк, хәзрәт! Сине генә күргәнем юкка...» —дип сүзен борды.

Ул, Вахид мулланы намазга озаткач, аның акыртын гына атлап урам буйлап китеп баруын караганда да теге фикердән котыла алмады.

«Чын да, шулай ук үземә көндәш алып бирсәм?..»

Иттифакый гына аның авызына эләккән «көндәш» дигән сүз бөтен фикеренә суык кушты.

Бердән, аның күз аллары ачылып китте.

Нинди зур куркыныч уй белән уйнаганын хис итте.

Көндәш?..

Әнә туганым абыстайның көндәше бар иде. Туганым абыстайның кизүе көнендә ашына керосин тамыза торган, түшәге астына үлгән мәче баласы сала торган, аның яккан мунчасына былчырак ыргытып исертә торган көндәш кебекме?..

Юк, юк! Мәңгегә юк!..

Ник алай?.. Менә карт җиңгинең дә көндәше бар иде бит: ул кечкенә чакта, теге шалкан йолкып кайткан көнне чибәр җиңги үлгәч, карт җиңги нинди елаган иде. Аның җеназасын күтәреп чыкканда нинди ачы тавыш белән: «Бәхил бул, бәхил бул!» — дип кычкырган иде. Үлек-гүр садакасын әнигә үзе китереп, нинди елап-елап чәй эчкән иде.

Шундый булса?..

Ул тагы шундый көндәшле әллә ничә хатыннарны искә төшерде. Шуларның кырык төрле җәфаларын, җәзаларын күзеннән кичерде.

Ләкин, ни өчендер, шуларның һәммәсендә дә көндәш белән торуның тышкы ягын гына карады. Тышкы ягын гына мөхакәмә итте. Тышкы уңайсызлыкларын гына йомшатырга маташты.

Менә инде, ул хәзрәтне өйләндерсә, үзенә көндәш алып бирсә?

«Көндәш» дигән сүз Сәгыйдәнең саф уйларында юыла-юыла ачысын бетерә төште; ул аны ул кадәр куркытмый башлады: ул шул сүз белән гади сүз кебек иттеребрәк кылына башлады.

Әйе, көндәш алып бирсә?

Ул хатын... әлбәттә, хатын түгел: кыз...

Шул кыз бик матур, түгәрәк алма кебек балалар бирә дә, хәзрәтнең шул баласызлык китеклегеен бетерә дә, үзе әллә кая читкә китәме?

Әллә нишли кебек тоелды. Тоелды гына да түгел, ул шул үз хәзрәтенең үзеннән башка хатын-кыз белән икесе арасында гына булган, булачак, булырга тиеш гаилә хәятына катышуын уйламады да, уйлый да алмады...

Ул бит Сәгыйдә белән боларның икесенке генә — башканыкы түгел.

Балалары юк икән, менә бер хатын аларга бала бирә. Ул бала әллә ничек туа?.. Ничек булса да була... Ләкин ул хәзрәтнең баласы була...

Уй шуннан узмадымы, шунда туктадымы? Ләкин ул үсте, ныгыды, беректе. Хәзрәтне өйләндерергә дигән төскә кереп тамырланды, бөреләнде, яфрак ярды. Бик озак эзләгән авыруына дару тапкан кеше кебек, Сәгыйдә тынычланып, рәхәтләнеп тә китте.

Шул эшне тиз-тиз булдыру өчен хәзрәткә дә сөйләмәкче булды, күңеленнән яраклы кызларны эзләргә дә тотынды.

Авылларындагы үзеннән сабак укыган, уртача гына бер мужикның кызына карарга килде.

Менә ул, Сәгыйдә, үзе яучы булып бара. Зөлфия абыстай самавыр куеп чәй янына утыргач: «Мин бит, Зөлфия абыстай, Галимәне бик яхшы бер урынга сорарга килдем. Дәүләт зур, дәрәҗә зур, кешесе яхшы, ләкин бер генә җитмәгәне бар: көндәш өстенә», — ди.

Зөлфия абыстай: «Кемгә соң ул, абыстай?» — дигәч, Сәгыйдә күзен дә йоммаенча: «Үз хәзрәтемә!» — ди.

Зөлфия абыстай аптырап кала. «Әллә абыстай гакылдан язды микән?» — дип шөбһәләнә. Бүлмәдәге Галимә дә тиз генә чулпыларын шылдыратып чыгып китә... Ләкин Сәгыйдә һаман шул сүзендә...

«Хәзрәт бик яхшы, дәүләтемез бар... фәлән-фәлән...» һәммәсен сөйли.

Бик озактан соң Зөлфия: «Абыстай, соң син үзеңә көндәш алмакчы буласыңмыни?.. Мин соң, абыстай, үзеңнән укыган кызымны ничек иттереп сиңа көндәшлеккә бирим?» — ди. Сәгыйдә, һаман шул үз юлында: көләкинәнә сөйли...

Кызны бирергә разый булалар... Менә туй... Никях та укылды, ди... Менә кияү алырга килделәр, ди...

Кияү алырга?..

Хәзрәт кияү булып барачак, ди.

Хәзрәт, Сәгыйдәнен хәзрәте, кияү булып барачакмы?

Теге елны Сәгыйдәгә кияү булып килгән хәзрәтме?.. Ул Сәгыйдә янында бикәчләп яткан кебек, Галимә янында да бикәчләп ятачакмы?..

Аның күз алдында бердән бөтен яшь гомер, бергә үткәргән бөтен матур минутлар үтте. Ул Сәгыйдәне үзенең бәхете-сәгадәте белән бөтенеләй томалады.

Ул шуларны яңы татыган, яңыдан күргән кебек булды. Хәзрәтнең бөтен кылынышларын, көлешләрен, сөюләрен, сөелүләрен хис итте.

Шулар, менә шулар бердән Сәгыйдәдән алынып, Галимәгә китәрме?

Хәзрәт, аның хәзрәте, менә шул матур минутларны, матур сүзләрне, йомшак сөюләрне Галимәгә багышлармы?..

Аның күңелендә Галимәгә каршы иксез-чиксез дошманлык туды.

Ул шул әдәпсез, остазының өстенә көндәш булып килгән хатынны — оятсыз кызны тетмәсен теткәләмәкче, изүен өзмәкче булды.

Сәгыйдәдән хәзрәтен, бердәнбер хәзрәтен алган өчен, талаган өчен үзәген өзмәкче булды.

Хәзрәтенең Галимәгә кылган — шул затсыз мужик кызы Галимәгә кылган шул илтифатыннан, аңарга чәчкән шул әрәм матур сүзләреннән ул хурланды, йир ярылса, йиргә керерлек булып хурланды.

Үзенең шулай мыскыл ителүеннән, хәзрәтеннән мыскыл ителүеннән янды, көенде.

Аның бугазына әллә ни тыгылды.

Аның күзеннән елгалап яшь, кайнар яшь агарга, хурланган, мыскыл ителгән йөрәктән кайнап чыккан яшь агарга тотынды.

Җылы-җылы фикерләре рәткә килә башлагач, ул:

— Юк, юк, мәңгегә юк... Хәзрәт минеке, хәзрәт минеке... Бирмим, бирмим!—дип кычкырды...

Ләкин шул туган фикер, никадәр ачы булса да, үсте, аның зәһәре никадәр тәмсез булса да, Сәгыйдәнең йөрәгенә кергәннән-керә барды.

Балага мәхәббәт, хәзрәтне бәхетле итәргә теләү — аның күңелендә көндәш ачысыннан көчлерәк чыкты. Ул акрын гына шул уйга өйрәнә килде. Гакыл белә «Хәзрәтне өйләндерергә» дигән карарына үзенең йөрәген өйрәтә башлады.

Шул эштә иптәш-ярдәмче итеп ул тагы китап — Коръәнгә кереште, ул тагы намаз-ниязга чумды.

Иске китаплардан изге хатыннарның тәрҗемәи хәлләрен эзләп, аннан рухына азык алды.

Әюб пәйгамбәр хатын 18 ел авыру иренең яраларын-җәрәхәтләрен юып торган. Ахырда, ирен ашатыр өчен бернәрсә булмаганга, матур толымын кисеп сатып, азык китергән...

Әллә нинди бер әүлиянең изге хатыны, иренең язу өстәлендә язуы бетүдән элек шәме беткәч, ирен эштән аермас өчен, зур толымын кискән дә, шуны майга чумырып, шәм иттереп яндырган...

Хәзрәти Хәдичә үлгән чакта, хәзрәти Рәсүл Хәдичә Разый Аллаһе ганһегә:

— Хәдичә! Аңда баргач, синең кыяметтә көндәшең булачак — фиргавен кызы Асия белән Мәрьямне күрерсең... аларга миннән сәлам әйт! — дигән.

Хәзрәти Фатыйманың:

— Ник, әти, әнинең үләр алдында күңелен рәнҗеттең? — дигән сөаленә каршы пәйгамбәр:

— Кызым! Анаңның изгелек дәфтәрендә һәр яхшылыкны күрдем. Ләкин көндәшкә сабыр итте дигәне булмаганга, шул юлын да тутырыр өчен әйтәм, — дигән.

«Минем башка савапларым булмаса да, гамәл дәфтәремнең шул бите тулса, мин дә хәзрәти Хәдичә ливасында кубарылырмын!»

Көндәшкә сабыр...

Көн үтте, ай үтте.

Сәгыйдә үзенең күңелен шул авырлыкка өйрәтә килде. Вакыт үткән саен, көндәшнең ачысы кимемәсә дә, Сәгыйдәнең ачыга чыдавы арта барды.

Аның күңеле ныгый килеп, ахырдан ул, үзенең шул корбанны итә алырлык көч җыйганны хис итеп, хәзрәткә мәсьәләне чиште.

Хәзрәт ашыга-ашыга җомгага хәзерләнә иде.

Сәгыйдә чапанны биргәч тә:

— Менә, хәзрәт, баламыз булса, җомгадан кайтуыңа балаң каршы чыгып торыр иде. Ул, зурая башлагач, синең белән бергә мәчеткә барыр иде, бергә кайтыр иде. Хәзер?.. Әллә, хәзрәт, сине өйләндерикме?.. — диде.

Шул сүз хәзрәткә шулкадәр ят тоелды, аның мәгънәсе хәзрәтнең уеннан шулкадәр ерак булды: ул чит бер телдә сөйләнгән сүз кебек кенә аны ишетте, аның мәгънәсенә дә ирешә алмады, аның тугрысында уйлый да алмады.

Тиз-тиз мәчеткә ашыкканнан-ашыкты.

Ләкин шул сүз, «ләфзаи морад» кына булса да, аның күңеленнән китмәде.

Әттәхият әл-мәсҗед намазы укыганда ул аның мәгънәсенә төшенгән кебек тә булды... Хотбәгә менгәч, ул шуның мәгънәсен иҗекли-иҗекли хотбәсен дә янлышты... Фарызда да аз гына сүрәи «Фатиха»дан соң рөкүгъга китмәде...

Ләкин кайткач та, Сәгыйдә белән бик ачык сөйләшеп шул уйны, шул «булмый торган» уйны баштан ыргытырга булды...

***

Җомгадан соң Хәйрулла агайның анасының зиярәтенә сүрәи «Мөлек» укып кайтканның соңында, Вахид хәзрәткә, элгәреге кыяфәттә, элгәреге самавыр, чәй белән көтә торган Сәгыйдә остазбикә каршы чыкты. Һаман элгәреге сүзе:

— Исәнме, хәзрәт? — булды.

Ләкин Вахид хәзрәт гомерендә беренче мәртәбә — ун еллык бергә тормышларында беренче мәртәбә — кашын төшереп, Сәгыйдәгә карамаенча, мыгыр-мыгыр гына җавап бирде.

Ул үзе дә шул табигый түгеллеккә, үзенең тавышының ятлыгына аптырап киткән кебек булды, «ни булды?» дип уянып киткән кебек булды...

Шуның сәбәбен табар өчен тирә-юнен күздән кичерде. Чәй ясап тора торган Сәгыйдәгә күзе төште. Берни дә юк... Һаман иске самавырлар, иске хуш чәй исе, иске җиһазлар...

Һәммәсе иске... Сәгыйдә дә иске Сәгыйдә... Ләкин... Аның күзенә сыек кына, сыек кына әллә ни сөртелгән...

Әйе, сөртелгән!..

Моңлык, кайгылык сөрмәсе тартылган...

Маңлаенда да яңы бер сызык бар...

Яңы...

Вахид аны күргәне юк иде... Шул сызык, шул моңлы күз өстендәге сызык Сәгыйдәнең төсенә бер башкалык, нәрсә икәнен әйтеп бирергә мөмкин түгел башкалык куша...

Ул Сәгыйденең йөзенә бер уйга килү, бер уйга туктау, сүзендә тору буявын сөртә...

Әйе, аның бөтен йөзендә әйткәненнән чигенмәү язылган.

Бу элгәре бит юк иде...

Әллә Вахид күрмәде генәме икән?..

Ул Сәгыйдәгә әллә ни өчен үпкәләгәнгәме, башка сәбәптән кәефе киткәнгәме, чәй дә аңарга элгәреге кебек нәшьәле чыкмады. Сәгыйдә әллә нинди сөальләр биреп сүзне озайтырга теләсә дә, сүз бәйләнмәде, озаймады.

Ул гадәттәгедән аз эчеп, шүрлектән калын бер китап алып, ривайәт эзләргә, түбән очтагы Касыйм балаларының аталарыннан калган малларын бүлүдәге ривайәтләр эзләргә кереште.

Озын иттереп өйрәнгән гарәпчәләрне укыса да, әллә нигә, алар аның башына кермәде. Ап-ачык иттереп китап Касыйм Сафиның угылына

тәрикәдән хисса чыгармаса да, ул гасабәләрнең хөкеменнән үтеп китеп, бәни-л-гыйлләтләр, бәни-л-әгьяннарга, зәвие әл-Хамнарга барып чыкты...

Шулардай әллә нәрсә казынды.

Эчендә әллә нинди үчне пошырып тора торган ят нәрсә, 12 ел мөддәтендә бер мәртәбә дә күрмәгән, хис итмәгән ят нәрсәне тойды, сизенде. Шул көтмәгән ят нәрсәдән, үги уйдан котылыр өчен тагы шуның сәбәпләрен эзләргә тотынды.

Аның күзләре Сәгыйдәнең күзләренә очрашты. Ул күзләр биниһайә тирән, төпсез кебек күренде.

Вахид теге ятлыкны биргән нәрсә, моның тыныч күңеленә теге үги дошман фикерне суккан нәрсә — шул күзләр икәнен бердән хис итте.

Сәгыйдә шуны аңлаган кебек, шул тирән күзләре белән хәзрәтнең йөрәгенә кадалган укны, зәһәрле укны күргән кебек, йомшак кына көлеп:

— Хәзрәт, синең әллә ник кәефең юк... —диде. Вахид хәзрәт ачуланган тавыш белән:

— Юкны сөйлисең! — дип җавап кайтарды. Вә үзе дә шул тавышның дорфалыгыннан, мәдләренең ямьсезлегеннән оялып та китте.

Сәгыйдә, йөзенә тагы көләчлек кушып, баягы күзенә тагы әллә нинди көч кушып:

— Хәзрәт, юкны сөйләмим. Менә бергә тордык, бергә яшәдек. Мин синнән бер авыз яман сүз, күңел калдырырлык бер эш күрмәдем... Унике ел бергә торамыз... Әлхәмделиллаһ, көнемез иркен... Дәүләтемез мул... Үзең беләсең... Ләкин, хәзрәт, боларга хуҗа кем?.. Болар кемгә кирәк? Мин, хәзрәт, менә шул ындыр тулы икмәкләремез, йорт тулы малымыз-туарымызның кирәген белмим... Мин алар белән нишлим? Шул зур өйләр, шул җиһазлар миңа хуҗасыз, иясез кебек тоела... Без шуларга хуҗа таба алмадык... Мин, хәзрәт, сиңа бала бирә алмадым... — Ул озын иттереп хәзрәткә карады.

Хәзрәт: «Бу тавышны, бу көчне Сәгыйдә кайдан алды? Әллә гакылга җиңеләя башладымы?..»— дип уйларга өлгермәде, Сәгыйдә тагы:

— Хәзрәт, монда мин гаепле, синең тормышың, шул тормышыңны мин бизәкли алмадым, шул тормышка мин китеклек бирдем... Сине бала мәхәббәтеннән мин мәхрүм иттем... Сине, хәзрәт, үлгәннең соңында догачысыз мин калдырдым... Шул бабадан бабага килгән михрабны хуҗасыз мин иттем...

Вахидның тамырлары, сеңерләре киерелә барса да, Сәгыйдәнең тавышында әмеранә бер мәдд булганга, ул аның сүзен бүлә алмады.

Сәгыйдә :

—Хәзрәт, син җигәрендә әле, сиңа әле, Аллага шөкер, өмет бетмәгән... шул өйләр, шул дәүләтләр, шул мәчет, мәдрәсәгә хуҗа, үзеңә дә, миңа да догачы калдыру өмете бетмәгән... Хәзрәт, сиңа өйләнергә кирәк!

Ул тагы тирән күзе белән хәзрәтне сөзде...

— Пәйгамбәрләр дә өйләнгән... Әүлиялар да өйләнгән... Шуның өчен, хәзрәт, менә мин сине өйләндерергә кирәк дигән уйга килдем... Сиңа яучы булмакчы булдым. Кызын да таптым. Үзе инсафлы. Үзе тәрбияле. Үзе укыган. Үзе чибәр. Фәхри абзый кызы Галимә... Миңа, Хәзрәт, рөхсәт бир! Мин Зөлфия абыстайга яучы булып барыйм...

Сүзнең ахырын әйтеп бетерә алмады, Вахид хәзрәт сикереп торды, тез өстенә куйган китабы төшеп китте. Ул ямьсез тавыш белән:

— Ахмак, тик тор!.. Авызыңны сугып ярырмын! — диде.

Шул сүзләрне ул Сәгыйдәгә гомерендә беренче мәртәбә әйтсә дә, шулкадәр куәтле чыкты: ул үз тавышыннан үзе куркып китте.

Күзендә уйный торган ачу чаткылары белән яндырыр өчен Сәгыйдәне бер мәртәбә сөзде.

Сәгыйдә һаман көләч йөзе белән, керфекләреннән батырлык чыгып тора торган, нурланган күз белән Вахидның күзен каршы алды.

Вахид, аның күзендә әллә никадәр мәхәббәт, шәфкать кушылган көч күреп, шуңарга ачуы чыдый алмаганны сизеп, ишекне бик каты ябып чыгып китте.

Шуннан соң Сәгыйдә, гүя шул сүзләрне онытkан кебек, шул уйга кайтмады.

Ләкин һәр тугры килгәндә акрынылап-акрынылап хәзрәтнең күңеленә: «Баласыз тормыш — хәят түгел, балалы булыр өчен икенче хатын алудан башка юл юк», — дигән уйны сугарга кереште.

Ул, хәзрәтнең балага мәхәббәтен тагы арттырыр өчен, авылның бөтен матур балаларын, әле берсен, әле берсен алып килеп сөя башлады. Әле берсе, әле берсе хакында хәзрәткә сөйләп, аның күңелендә балалы тормыш манзараләрен төрле-төрле матур буяуда күрсәтә килде.

Аның белән генә дә хәзрәтне аударырга мөмкин булмагач, Сәгыйдә хәзрәтнең дикъкатен икенче хатыннарга, икенче кызларга таба борырга карар бирде.

Авылда мулла гаиләсендә бу бик авыр булганга, хәзрәтнең «Сәгыйдәгә башка дөньяда хатын юк» дигән фикере бик тирәндә торганга, ул бик осталык белән генә шул уй белән сугышырга кереште. Хәзрәт өйдә чакта авылның матур кызларын эш белән кунарга чакыра башлады; төрле юллар белән хәзрәткә шуларны ямьле иттереп күрсәтергә тотынды.

Бер мәртәбә ул матураеп, үсеп җиткән Фәридәне: «Кызым, бар, хәзрәт өйдә юкта өйләрне җыештырып чык!»—дип, Хәзрәт өстенә тасрайган Фәридәне йибәрде.

Бер мәртәбә ул бүлмәдә чигеш чигеп тора торган Галимәне күрсәтер өчен: «Хәзрәткәем, бүлмәдән комганыңны үзең ал! Сыерым моңаеп тора», — дип, Галимә өстенә кертте.

Бер мәртәбә, белмәмешкә салынып, хәзрәт түренә, хәзрәт китап карап тора торган бүлмәгә, өч-дүрт кызны берьюлы кертте.

Шулай ук, белмәмешкә салынып, кызларның «Мөхәммәдия» тавышларын да хәзрәткә ишеттерде.

Берсенең кубыз уйнап, икесенең биюен дә хәзрәткә күрсәтте.

Ләкин шул күрүләр, очрашулар вакытлы гына булса да нә хәзрәтнең күңелендә вәсвәсә тудырды, нә гаилә тормышын үзгәртү хакында бер уй башка сукты.

Ул һаман элгәреге игътикад белән — «Сәгыйдәдән башка хатын юк» фикере белән яшәде дә яшәде.

***

Беркөнне хәзрәт әллә нишләп үлек күмгән җирдән суык тидереп кайтты. Икенче көнне намазга чыга алмады. Өченче көнне җомгага да бара алмады.

Дүртенче, бишенче көннәрне хәзрәт ятактан тормады. Алтынчы, йиденче көннәрне хәзрәт каената хәзрәтне алдырды, күрше авылдан берничә мулланы чакыртып, васыять язарга кушты. Фидиясен әйтте. Бурычлары чыкса, түләргә сумма күрсәтте. Мәдрәсәдә укыганда йомыркасын урлап ашаган Шәхми абзыйның балаларын ризалатырга кушты. Хаҗына алты йөз сум аерды.

Шуннан калган йортын-йирен, мал-туарын — бөтен дәүләтен Сәгыйдәгә яздырды.

Ләкин Сәгыйдә:

— Хәзрәт, мин синсез нишлим? Мин аның белән синсез нишлим? Хәзрәткәем... Миңа калдырма!..—дип ялынырга тотынды.

Вахид хәзрәт, күңеленнән кемгә калдыруны эзләсә дә, Сәгыйдәдән башка кешесе булмаганга, таба алмады.

Менә мәхәллә картлары күрешергә керделәр.

Картлар керә-керә үк күзләре яшәрсә дә, хәзрәт авыру тавышы белән:

— Җәмәгать! Сезгә каршы гөнаһым зур. Имамлык Вазыйфасын үти алмадым. Мине Аллаһе Тәгалә алдында тоткар итмәңез... Мине кичереңез... Миннән мәхәллә халкы бәхил булсын! — дигәч, бөтенеләй яшьләрен тота алмадылар.

Берсе:

— Хәзрәт! Авылымызны яктырткан идең, мәсҗедемез, мәдрәсәмезгә нур керткән идең, безне калдырып китәсең? Михрабыңны кемгә калдырасың? — диде.

Вахид хәзрәтнең авыру башында шул уй тагы чуалчык булып басты.

«Михрабыңны кемгә калдырасың?..»

Шул михрабта менә йөз дә унбер ел бер нәселнең балалары имам булып килделәр.

Инде ул буын өзелә!

Вахид михраб иясе имам калдырмый... Вахидның баласы юк...

Вахидның үзенең китапларын, читләренә хашияләр язган китапларын да калдырырга, бабадан атага, атадан балага калып килгән китапларны да калдырырга шәкерт угылы юк...

Вахидның дәүләтен, мал-туарын, йортын-йирен дә калдырырга угылы юк...

Вахидның «Әнкәңне тыңла, әнкәңә итагать ит!» дип васыять әйтеп калдырырга да угылы юк...

Юк...

Ичмасам, шул тәрбиягә алган балалар да яшәмәде!..

Шәт, Сәгыйдә теге көнне хаклы иде...

Ул озын иттереп, зәгыйфь күзендәге бөтен көчен җыеп Сәгыйдәгә карады. Аның күзендә: «Мине кемгә калдырасың?» — дигән сөаль күрде.

Күңелендә әллә нинди, гомерендә булмаган бер көч белән уй-мәсъүлият уе, шул Сәгыйдә алдында мәсъүлият уе туды...

«Бу хатын, бөтен барлыгын миңа бирде. Минем тормышымны оҗмах ясады... Хәзер менә үләм, моңар ни калдырам?.. Моны кемнең каравына тапшырам?..

Теге вакытта аның сүзен тыңлаган булсам, бәлки аның хәзер бер угылы булыр иде...

Шул җиде буыннан килгән михрабның иясе булыр иде...»

Ул тагы фикерен өзеп йибәрде, тагы уянды, тагы күзен ачты. Сәгыйдәнең кайгылы, моң карашы тагы шул мәсьәләне яңартты.

Менә әллә ни булды... Вахидта үзенең угылын күрәсе килү, менә шунда, хәзер үзе яткан түшәк янында, угылын күрәсе килү туды.

Бу хис бөтен тирә-юнен каплады... Бөтен мәсьәләләрне онyттырды... Бөтен кешеләрне, якыннарны томалады...

Бөтен көчен-куәтен бергә җыеп, шул угылын «эзләргә» күзен ачты.

Сәгыйдәнең тирән күзләрендә — яшь белән кызарган кабаклары арасында яшеренгән томанлы гына, моң гына күзләрендә ул шул угылның кайдалыгын тапты.

Аның күз алдына бала күтәреп Галимә килеп басты.

Ул саташа башлады: угылы белән, Сәгыйдә белән, Галимә белән саташа башлады.

***

Озын сырхаудан озынылап терелгәндә хәзрәтнең уйларга вакыты бик күп булып, шул очсыз уйдан бер нәтиҗә чыгардымы, әллә шул авыр хәстәлек хәзрәтнең башында иске уйлар, иске тойгыларны җимереп төшереп, алар урынына яңа фикер, яңы хис тудырдымы, иллә башкача берәр сәбәп булдымы, алар яңыдан бер мәртәбә сөйләмәенчә дә шул фикердә Сәгыйдә белән бер сүзгә килделәр.

Шуны да сүз белән түгел, тойгы белән, әллә ничек, күзгә-күз карашу белән аңлаштылар.

Шуның ничек булуын да озын иттереп уйлашмаенча, сөйләшмәенчә таныштылар, белештеләр.

Шуның өчен Сәгыйдә: «Хәзрәт, сәфәр ае кергәнчә әллә эшне тәмамлыйкмы?» — дигән сөальгә дә хәзрәт, искедән сөйләнеп беткән кебек:

— Үзен кара, остазбикә! — диде.

Шул сүзне әйткәндә аның күңелендә ятлык булмаган кебек, сүзендә дә фәүкыльгадә бер карар хакында сөйләнгәнлекне белдерерлек һичбер төрле мәд булмады.

Сәгыйдә: «Мин, соң, хәзрәт, алай булса, барыйм!» — дигәч тә хәзрәт тагы, кемгә икәненең әллә кайчан сөйләнеп, беркетелеп куйган кебек иттереп:

— Соң, Зөлфия абыстай әле ишаннан кайтканмы? — диде. Сәгыйдәдән «Әйе!» җавабын алгач, ул тагы, гади бер эш эшләнде дә, тагы бер икенчесенә рәт житте дигән кебек:

— Мин, соң, Сәгыйдә, базарга барып килмәемме? — диде.

Сәгыйдә: «Барасың, хәзрәт, барасың!» — дип аның сүзен йөпләде; хәзрәткә, ниләр алу хакында әмерләр бирде.

Кич буе алар икәүләп бөтен туй яракларын санап чыктылар. Бөтен туйның вакларына кадәр планнарын төзеделәр. Туй-төшемдә була торган бүләкләрне дәрәҗәсе дәрәҗәсенә күрә бүлеп кәгазьләргә яздылар.

Шулар өчен кирәкле булган акчаны да бергә санадылар.

Боларның һәммәсенә дә икесе дә бер дәрәҗә эшлеклелек, бер дәрәҗә кәефлелек куштылар.

Әллә үзләрен үзләре оныттылармы?.. Әллә берсенең кияү булып, икенче хатын алырга йөрүен, берсенең карт хатын булып, көндәш китерергә әзерләнгәнен хәтердән чыгардылармы?..

Шул эшләрен һәммәсен угылларын өйләндерә торган карт белән карчык кебек тыныч, кызларын үзләре теләгән урынга бирә торган абыстай белән абзый кебек шат эшләделәр.

Гүя бу туй боларның берсенә дә шатлыкка башка бер нәрсә дә китермәячәк, гүя бу туй боларның унике еллык шул сөешүләренә, дустлыкларына күңелсез бер сызык та сызмаячак.

Шул туй кәефе белән Сәгыйдә базарга китәр алдыннан тагы бөтен бүләкләр, бөтен кирәк-яракларны санап та чыкты.

Шул ук туй кәефе белән ул Зөлфия абыстайга яучы булып та барды.

Шул ук кәеф белән хәзрәтне кияү итәргә дә хәзерләде.

Ул шул ук кәеф белән туй ашлары пешерде.

Аларның яхшы булып уңуы өчен шулай ук тырышты.

Никях көне җиткәч, шул ук кәеф белән хәзрәтне үзе мунчага кертте, үзе яжы күлмәкләр кидерде.

Үзе хәзрәтнең сакалын, мыегын төзәтте.

Кияүне алырга килүчеләрне дә үзе ашатып, хәзрәт кояш баеганчы барып керерлек булсын дип, ашыктырып, үзе тәһарәтләндерде.

Һәммәсе хәзер булып, хәзрәт кияүчә киенеп йитеп, «Аятелкөрси» укырга утыргач та, Сәгыйдә акыртын гына хәзрәттән түбәнгә тезләнде вә озын иттереп кулларын Алла дәргаһына сузды.

Бүлмәдәге хатыннар да, түрдәге кияү алучылар да тезелделәр, тезләнделәр.

Хәзрәт элгәре гади тавыш белән сүрәи «Фатиха»дан башлап Коръән укырга тотыныса да, бара-тора аның күңеле тулып киттеме, тавышы моңланды. Аның саф тавышына күз яше кысылды, ул, көчкә генә очлап чыгып, кулын күтәреп, озын догадан соң йөзен сыйпаганда битеннән ике бөртек яшьне дә сөртеп алды.

Сәгыйдә һаман салкынканлылыгын югалтмады.

Ул, хәзрәт торып ишеккә бара башлагач та, элгәреге кебек үк көләч йөз белән: «Хуш, хәзрәт!» — дип кулын сузды.

Хәзрәтнең кайнар кулын озын гына тотып, хәзрәтнең йөзенә, күзенә карап: «Аллаһе Тәгалә хәерлегә кылсын! Бисмиллаһиррахман, хәзрәт, боер, хәзрәт!» — дип, юл ачты.

Атка утыргач та хәзрәтнең: «Хуш, Сәгыйдә!» — диюенә каршы тагы ук шул шатлыклы, көләч йөз белән: «Хуш, хәзрәт, хуш, сау, сәламәт бул!» — диде.

Атлар күтәрелеп, кыңгыраулар шалтырап, түбән очка төшеп киткәч тә, аның йөзенә, төсенә кайгылык, кәефсезлек чыкмады.

Ул кияү озатуны карарга килгән әллә никадәр балага да, туй төсе булсын дип, бүләкләр бирергә онытмады.

«Абыстайның хәле бик авырдыр» дип бергә кайгырышырга килгән авыл хатыннарының күз яшьләренә дә көлеп караудан башкача җавап бирмәде.

Гади көндәге кебек, ул ахшамдан соң өйләрен җыештырып бетерде. Ястүдән соң, гади көндәге шикелле, урын салды.

Түшәкне кабартты, ястыкны күпертте, япмаларны пөхтәләп япты, юрганны ачты, хәзрәт ята торганча иттереп ястыкның мамыгын теге якка таба төртте.

Менә хәзер хәзрәт ястүдән кайтыр кебек иттереп, шуларны ашыга-ашыга, тиз-тиз эшләде.

Ашыга-ашыга үзенең кичке күлмәген алыштырды.

Ләкин, ни өчендер, ул шул урынга якын килә алмады...

Ул унике елда беренче мәртәбә шул урыннан суыклык хис итте.

Беренче мәртәбә шул урыннан үгилек исе тойды, беренче мәртәбә шул урынның ят икәнен, бөтенеләй ят икәнен сизде.

Бердән бөтен йөрәген салкын тимер белән каерып алган кебек булды. Бөтен тәнен суык, зәмһәрир суыгы тотты.

Тәне өшеде. Җаны сыкрады.

Күңеле ташыды.

Йөрәге ярылырга йитте.

Ул, шул ятлык килә торган урынга якын бара алмаган кебек, шул суыклык аны бәйләгән, туңдырган кебек, читкә дә китә алмады.

Ул урын янындагы намазлыкка утырып кулын күтәрде. Ике күздән мөлдерәп ага торган күз яшьләрен туктата алмавын, кайгыга сабырсызлык булмасын дип, Аллага ялварырга, ялынырга башлады.

Шул ук намазлыкта ул оеп та китте.

Шул ук намазлыкта бер уянып, бер калкып ул төнне кичерде!..

***

Икенче көнне иртүк кияү чаенә Сәгыйдәне алырга килгән атка утырып баргач, калтырабрак, аптырабрак каршы чыккан Зөлфия абыстайга да ул һаман элгәреге кебек көләч йөз белән: «Исәнме?» — диде.

Өй арасында йөри торган Зөлфия абыстайның киленнең кызын да элгәреге кебек итеп сөйде.

Хәзрәт бикәчли торган өйнең ишегенә җиткәч кенә бердән, алдында упкын ачылган кешедә була торган кебек кот очу аны биләде.

Шул өйгә, шул ишеккә каршы бөтен тәне-җаны дошманлык белән тулды.

Аның аяклары: «Юк, шул өйгә, шул минем бәхетемне алган өйгә кермим!» — димәкче булды.

Аның күзләре: «Шул унике еллык хәзрәтемне, унике еллык үземнеке генә булган хәзрәтемне башкаларның кулында, кочагында булганын күрелә торган өйгә кермим!» — димәкче булды.

Сәгыйдә тагы көчен җыйды.

Тагы тазарып, «бисмилла» әйтеп ишекне ачты.

Аның күзе бөтен шул өйдә булган, булачак нәрсәләрне күрәсе килгән кебек бердән түргә атылды.

Аның күзләре Галимәнекенә очрарга өлгермәде: Галимә, иелеп, башын бөкте, йөзен яшерде.

Аның күзе хәзрәтнең йөзен сыйпарга өлгермәде: хәзрәтнең бөтен өстеннән бер калтырау, олуглар алдындагы бер калтырау узды.

Хәзрәт туп-тугры иттереп Сәгыйдәгә карарга батырчылык кылмаса да, Сәгыйдә һаман шул көләч йөз, һаман шул хәтфә тавыш белән: «Исәнме, хәзрәт?» — дигәч, ул акыртын гына күзен күтәрде.

Сәгыйдә кара сыманрак күлмәк киеп, кара өстендә ак бизәкле яулык бәйләгән.

Йөзе балавыздан ясаган кебек ап-ак.

Күзләре ут кебек яна, аларның төпләре тәмам беткән — упкынга әйләнгәннәр.

Маңлаена әллә нинди бер зурлык чыккан.

Бакышы — падишаһлар бакышы...

Йөреше — баһадирлар йөреше.

Ул акыртын гына, эчендәге зур бер кыйммәтнең төшүеннән курыккан кебек кенә хәрәкәт итә.

Ул алга атлаган саен шундагы кешеләрне, өйне, бөтен тирә-юньне вакландыра бара.

Ул якынайган саен зурая, үсә бара.

Вахид бердән сикереп торды.

Кояшка караганда күзнең чагылуыннан курыккан кебек, оялып кына Сәгыйдәгә таба карады...

Аның падишаһ кебек газамәтенә сыгыныр өчен, тиз-тиз каршы барып, күңеленнән аның алдына тезләнде.

Үзе кызарып, үзенең кечкенәлегенә кызарып:

— Исәнме, Сәгыйдә? — дип, калтырый-калтырый гына күрешергә кул сузды.

Сәгыйдәнең суык кулын алгач, йөрәгенә зур салкын агым кереп китеп, тагы аны өшетте, дерелдәтте.

Сәгыйдә Галимә белән күрешкәндә дә көләчлеген югалтмады.

Хәзрәт аны үзеннән югары утыртканда, гомерендә беренче мәртәбә үзеннән югары утыртканда да, ул үзенең кәефен, көләчлеген бетермәде.

Ул чәй янында, хәзрәт белән бик матур сөйләгән кебек, Галимә белән дә бик йомшак, бик шәфкатьле кылынды.

Чәйне тәмам итеп, күрешеп чыкканда да, икесенә дә бәхет-сәгадәт теләгәндә дә үзенең төсен дә, йөзен дә үзгәртмәде.

Сәгыйдә чыгып киткәч тә хәзрәт бик озак Сәгыйдәнең соңгы сыйфатын, сынын күз алдыннан җибәрә алмады. Шуның алдында иелгән башын күтәрә алмады.

Бөгелгән тезен турайта алмады.

Шул көндәшкә каршы, падишаһ кебек олуг, фәрештә кебек шәфкатьле көндәшкә каршы Галимә дә дошманлык, көндәшлек хисе били алмады.

Аның дошманлыгы Сәгыйдәнең йомшаклыгына, аның балага йомшаклыгы кебек шәфкатенә бәрелеп эреп киткән кебек булды.

Аның көндәшлеге Сәгыйдәнең олуглыгына, биеклегенә, падишаһ кебек биеклегенә бәрелеп югалып киткән кебек булды.

Хәзрәт, бикәчләүне бетереп, Галимәне өйгә төшергәч тә шул хис — Сәгыйдәнен олуглыгы хисе кимемәде.

Галимә мулла хатын булып китеп, мәҗлесләргә йөри башлагач та, бөтен эшләр, бөтен хәрәкәтләрнең Сәгыйдәгә ияргәнлеге бетмәде.

Шунысы гаҗәп: Галимә аналыкка чыгып бала тудыргач та, хәзрәткә дә, Галимәгә дә чын ана Сәгыйдә булып урынлашты.

Ул гына да түгел, балалар, үсә башлап, беренче сүзне әйткәндә дә иң беренче «әннә, әннә» дигәнне Сәгыйдәгә эндәште. Зурая башлагач та бөтен балалар, чын әни — Сәгыйдә дип ышанып, Галимәгә бик озакка кадәр «әни» дияргә базмадылар.

Аңлый башлагач кына көчләнеп «әни» дип йөрсәләр дә, аны һәрвакыт икенче дәрәҗә әни иттереп йөрүдән котыла алмадылар.

Балалар күбәйде.

Йорт-йир бала белән тулды. Бала тәрбиясе, бала мәшәкате хәзрәтнең дә, Сәгыйдәнең дә бөтен тормышын тутырды.

Алланың биргән бер елында Галимә абыстай йә бер кыз, йә бер угыл багышлап торса да, хәзрәт үз кулы белән метрикә дәфтәренә исемен «атасы Вахид, анасы Галимә» дип язып торса да, ул үзен-үзе һаман бер хатынлы иттереп хис итте; бер хатынлы иттереп уйлады; бер хатынлы иттереп торды.

Галимә һәрвакыт бергә булса да, Галимә хәзрәткә дә, Сәгыйдәгә дә матур балалар багышласа да, әллә ничек, ул хәзрәткә хатын булып, бала анасы булып күренмәде.

Ул шунда җарияме, кәнизәкме?.. Әллә... әллә нәрсә генәме булды да калды.

**Искәрмәләр һәм аңлатмалар:**

*Игътикад итү* — ышану.

*Мәсьүлиятле* — җаваплы.

*Имам могыйнь, лявазим имам* — имиага тиешле эшләрне эшләргә ярдәм итүче.

*Мөяссәр итсә* — насыйб итсә.

*Ливасы* — байрагы.

*Кыйраәт* —уку, Коръәнне яттан кычкырып уку.

*Фи сәбили Аллаһ* — Алла юлында.

*Кабзыятьләнү* — каушау.

*Әфәлем төрле* — төрле-төрле.

*Грифтар булу* — дучар булу.

*Барига* — бияләй (мишәр сөйләшендә).

*Истикамәт* — тугрылык, намуслылык.

*Мәкруһ күрми* — начар күрми.

*Җәсәд* — гәүдә, тән.

*Салаты мөнҗия* —котылдыру догасы.

*Мөрәккәб* — барлыкка килгән, кушылган.

*Мәдд* — аваз.

*Ингыйкас* — чагылу, нурларның кире кайтуы.

*Татбикат* — яраштыру

*Иттифакый* — очраклы рәвештә.

*Сахиб* — хуҗа, ия.

*Тәфсыйлат* — җентекләүләр.

*Тәхәллел* — аерылышу.

*Лива* — байрак.

*Ләфзаи морад* — тел генә әйткән теләк.

*Нәшьәле* — дәртләндерерлек, күңелгә ятышлы

*Тәрикә* — үлгән кешедән калган  мал-мирас.

*Хисса* — әлеш.

*Гасабәләр* — ата ягыннан булган туганнар.

*Бәни–л–гыйлләтләр* — бу урында: ярлылар.

*Бәни–л–әгъяннар*  — бу урында: байлар, дәрәҗәле кешеләр.

*Зәвие әл–Хам* —Хам нәселе  ( байлыклар).

*Мөддәт* — вакыт (арасы)

*Әмеранә мәдд* — боеру авазы.

*Хашия* — китап бите читендәге язма–искәртмәләр.

*Мәсьлият* — җаваплылык.

*Фәукыльгадә* — гадәттән тыш.

*Дәргяһына* — мәрхәмәтенә, ягъни күккә таба.

*Газәмәт* — олылык, бөеклек.

*Зоһур итү*— барлыкка килү.

*Монгакыйс* — киресенчә.

*Нәзарияләр* — карашлар.

*Кальб* — күңел.

*Халәте рухия* — рухи халәт.

*Сәнгате нәфисә* — нәфис сәнгать.

*Тамак толып* — төлке тиресеннән тегелгән толып.

**Остазбикә** — Повесть беренче тапкыр Мәскәүдә «М.О.Аттай и Ко» типографиясендә басылып чыга. Тышлыкта язылу вакыты «28 декабрь [1914] — 24 нче гыйнвар, 1915 сәнә, Мәскәү» дип күрсәтелгән. Нашире Г.Исхакый. Сигезтомлыкта: 8 нче жилд, 1 нче китап, 79 бит. Китапта басылу елы күрсәтелмәгән, әмма әсәрнең 1915 елның 28 маена кадәр басылып чыгуы билгеле. (Шушы биттәге искәрмәне карагыз.)

Моңарчы Г.Исхакыйның «Мәҗмугаи асәре» Казанда «Гасыр» нәшриятында басылып килә. Мәскәүдә Г.Исхакый нигезләгән «Ил»

гәзитәсендә мондый хәбәр бар: «Ил» гәзитәсе әлегә кадәр кеше матбугатында басыла иде. Петербургта татар матбугаларының камил куелган булмавы «Ил»нең нәшерен байтак читенләштерә иде. Шуңар күрә «Ил», яңа гына аякка басып килә торган бер гәзитә булса да, үзенә махсус матбага куярга мәҗбүр булды. Бу нумирымыз — бергә «Ил» матбагасы эшли башлаган саннардыр. Гаяз әфәнденең «Мәҗмугаи асәре»ннән «Гасыр китапханәсен»дә басылмый калган әсәрләре шул формада һәм том саннары «Гасыр»дагысының дәвамы итеп, «Ил» матбагасында басылачактыр». (1914 ел, 23 июнь.)

Повестька язган рецензиясендә Г.Гобәйдуллин болай ди: «Иң мөһим, иң кыйммәтле җәһәт —иң нечкә рухи халәтләрне тасвирда. Бу тасвирлар шулкадәр табигый, шулкадәр киң ки, «Яшь йөрәкләр»дәге мондый тасвирларны укыгандагы күк бер ару сизелми. Монда тасвирлар заказ буенча бу куәтле яисә зәгыйфь ихтыярлы бер кеше булып чыксын дип алдан уйлап куйган шаблон белән язылмаган. Монда адәмнең йөрәгендәге тойгылар, мондагы сызыкларның алмашынуын тасвирлар, бу халәтнең процессы вә үзе күк табигый... Җанлы хәйваннар арасында иң кызык бер рухи хәл дә — күбәергә теләү инстинктыдыр. Ләкин хәйваннарда ул каба һәм садә рәвештә зоһур итә. Хәтта без ул инстинктка китереп чыгарган хиснең ни рәвештә булганын белә алмыймыз... Ләкин шушы физиология җәһәтеннән табигать туп-тугры биргән нәрсәнең хәйваннар падишаһы кешеләргә ни рәвештә монгакыйс булганын, бу хәйвани хиснең адәмнәрдә нинди вөҗдани тойгылар биргәнен белүе бик кызык, бик мөһим бер мәсьәләдер. Монда коры фән иясе, ачы нәзарияләр белә баш вата торган бер галәмнән бигрәк, бу мәсьләне тасвирны сизгер кальбле, күзгә күк төрле кешеләрнең халәте рухиясен үзенә төшереп алырга булдыра торган рухлы сәнгате нәфисә әһелләреннән көтә аламыз. Шуңар күрә дә Гаяз әфәнде бу мәсьәләне тасвиры белә гади укучыга гына түгел, фән ияләренә дә азык бирә ала». *(Остазбикә.— Казан, 1915, 28 май.)*

Повесть Г.Исхакыйның «Зиндан» җыентыгында басылды.

Текст беренче басмадан алынды.

*Кадер кичәсе* — рамазан аеның 27 нче төнендә уздырыла торган мөселман бәйрәме. Бу төндә җиргә Коръән иңгән, мөселманнарның дога укып теләгән теләкләре кабул ителергә мөмкин. Шуңа күрә мөселманнар бу төнне йокламый үткәрәләр: мәчеттә җыелып дога укыйлар, Коръән укыйлар. Г.Тукай үзенең «Кадер кич» дигән шигырендә болай ди:

Бу кадер кич елда бер кич — барча кичләр көзгесе;

Сафланыр таптан бу кич мөэмин күңелләр көзгесе.

*Гарәфә көне* — корбан бәйрәме буласы көннең алдагы көне. Согуд Гарәбстанындагы Мәккә шәһәреннән 30 чакрым көнчыгыштарак урнашкан Гарәфәт тавы исеменнән алынган. Хаҗга баручылар бәйрәм көнне шул тауга барып дини йолаларын үтәгәннәр.

*Кыямәт көне* — дини тәгълимат буенча: ахырзаман җитеп, Исрафил пәйгамбәр сур өргәннән соң, үлгән кешеләр барысы да терелгәч, аларга Алла тарафыннан үткәрелә торган хөкем, суд көне.

*Билал разый Аллаhе ганhе* — Алла Билал белән риза булсын. Билал — Мөхәммәд пәйгамбәрнең азан әйтүче беренче мөәззине.

*«Мөхәммәдия»* — төрек шагыйре Мөхәммәд Чәләби Язычы угылы (1451 яки 1453 елда үлгән) тарафыннан төзелгән, Мөхәммәд пәйгамбәр һәм мөселманнар турындагы дини-әхлакый үгет-нәсихәттән гыйбарәт тезмә әсәр; татарлар арасында киң таралган булган.

*Кытат* — XVII—XVIII гасырларда Казанда һәм тирә-як төбәкләрдә урнашкан фабрикаларда киндердән сугылган тукыма.

*Манчестер* — Англиядә яки Россиядә сугылган тукыманың бер төре.

*Талир тәңкә* — талирдан эшләнгән чулпы тәңкәсе. Талир — XVIII гасырда немец дәүләтләрендә чыгарылган өч маркалы көмеш тәңкә — озак вакытлар Россиядә дә йөргән.

*Хәситә* — хатын-кызларның алтын-көмеш акчалар, ука һәм төрле кыйммәтле ташлар белән бизәлгән, күлмәк өстеннән күкрәккә киеп куела торган бизәнү әйбере.

*Хәзрәти Ибраһим бит санәм сатучының баласы булган* — Ибраһим пәйгамбәрнең әтисе потларга табынган, биредә шул риваятькә ишарә.

Хәзрәти Муса бит Фиргавеннең тәрбиягә алган угылы булган. — Дини риваят буенча, Мисыр Фиргавене янына күрәзәче килеп, шул җиргә күчеп яши башлаган Бәни-Исраил кабиләсендә бер ир бала туачак һәм ул илеңне таратачак, тәхетеңне алачак, ди. Бу хәл булмасын өчен Фиргавен Бәни-Исраил халкының һәр йортына кешеләр куя, барча туган ир баланы үтерергә боера. Нәкъ шул вакытта дөнья йөзенә Муса галәйһиссәлам килә. Баласын саклап калыр өчен анасы аны сандыкка сала да, Аллага тапшырып, Нил елгасына агыза. Сандыкны Фиргавен хатыны Асия, күреп ала. Баланы уллыкка ала, Мусаның әнисен сарайга сөт анасы итеп ала. Фиргавен үзен Алла дип белдерә, Мусаның халыкны Алланың берлегенә ышанырга өндәгәне өчен аңа явызлыклар кыла. Биредә шул риваятькә ишарә.

*Салават әйтү* — «Саллаллаһу галәйһи вә сәлләм» («Аллаһе Тәгалә аңа изге догада булсын һәм сәлам ирештерсен») дигән гыйбарәне әйтү.

*Данадар бүрек* — бик вак күксел илтердән яисә каракүлдән тегелгән цилиндр формасындагы бүрек. Андый бүрекне гадәттә муллалар, ишаннар, диндар байлар кигән.

*Гошер* — мөселманнардан ярлылар өчен алына торган салым. Ул барлык уңышның уннан берен тәшкил итә. Мөселман илләрендә гошер дәүләт

казнасына кергән, ә патша заманында Рәсәйдәге мөселман халыклар аны ярлыларга өләшкән, руханиларга биргән.

*«Әлхэмде» сүрәсе* — Коръәннең беренче — «Фатиха» сүрәсенең халык телендәге исеме.

*Гүр садакасы* — үлгән кешенең гөнаһларын йолдыру өчен, мәет өстендә әйтеп, аның өчесе узганчы бирелә торган аяклы мал.

*Нәфел садакасы* — өстәмә гыйбадәт (намаз) садакасы.

*Салаты мөнҗия* — котылдыру догасы.

*Рәҗәп, шәгъбан рузасын тотарга вәгъдә бирде* — сүз ай елының җиденче, сигезенче айларында тотыла торган өстәмә ураза турында бара.

*Хуҗалар өстенә барып корбан чалдылар* — Хуҗалар тавы — Биләр янында изгеләр тавы. Идел буе мөселманнары анда элек-электән хаҗга барган кебек йөргәннәр.

*Чәһаръяр гыйзам* — Мөхәммәд пәйгамбәрдән соң килгән бөек дүрт хәлифә: Әбүбәкер, Гомәр, Госман, Гали.

*Мулла Морад* (XVIII) — дин һәм милли азатлык җитәкчесе, әдип. Болгарчылар хәрәкәтен оештырган өчен Сенат хөкеменә тартылган. Әмма 1772 елның башында азат ителгән.

*Рамазан* — мөселман календаре буенча тугызынчы ай исеме, мөселманнар өчен изге хисаплана. Ул айда Коръәннең иң беренче аятләре иңдерелгән. Бу айда ураза тоталар.

*Бисмиллаһи әлләзи* — Коръәндә еш очрый торган аятьләрнең баш өлеше.

*Гыйддәт* — ирсез калган хатынның кияүгә бармый торырга тиешле вакыты.

*Рәкәгать* — намазның аягүрә тору, иелү һәм башны җиргә куюны эченә алган бер өлеше.

*«Колһуалла»* — Коръәндә 112 нче —«Ихлас» сүрәсенең халык телендәге исеме.

*Әттәхият әл-мәсҗед* — мәчетне мактау намазы.

*Рөкугъ* — намазда кулларны тезгә куеп иелеп тору.

*Сүрәи «Мөлек»* — Коръәндә 67 нче сүрә, «Тәбарәк» сүрәсе дип тә йөртелә.

*Хам* — Нух пәйгамбәрнең дүрт улының берсе. (Калганнары: Яфәс, Сам, Кинган.)

*Хашия* — китап бите читендәге язма-искәрмәләр.

*Сәфәр* — ай елының икенче ай исеме.

*«Аятелкөрси»* — Коръәндәге «Бәкара» («Сыер») сүрәсенең 255 нче аяте. Анда, нигездә, Алланың сыйфатлары санала: тере, һәрвакыт уяу, бар нәрсәне дә белә, аның тәхете җирләрне дә, күкләрне дә иңли.

*Ахшам* — кояш баеганнан соң укыла торган намаз.

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 2 том. - Казан:
Татарстан китап нәшрияты, 1999. Б.254-300.